# Роберт Миңнуллин

# Күңелләр нечкәргәндә...

*Яңа шигырьләр*

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2004

УДК 820/89(470)
ББК 84 (2 Рос=Тат)–5
М 57

**Миңнуллин Роберт**

М 57 Күңелләр нечкәргәндә... : Шигырьләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. — 175 б.

ISBN 5-298-01428-3 © Татарстан китап нәшрияты, 2004

*Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Х.-К.Андерсен, М.Җәлил, А.Алиш, Ф.Кәрим исемендәге әдәби бүләкләр иясе, күренекле шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе Роберт Миңнуллин укучыларга үзенең яңа китабын тәкъдим итә. Китапка шагыйрьнең соңгы вакытта язылган лирик шигырьләре тупланган. Мәхәббәт тулы якты хисләргә, татлы сагыш-моңнарга, тормыш, гомер турындагы тирән уйлануларга бай шигырь юллары шигърият сөючеләрнең күңелләренә хуш килер дигән өметтә калабыз.*

## *Мин яратам сезне, чордашларым!*

Мин яшимен сезнең арагызда,
Мин яшимен сезнең белән бергә.
Барып була сезнең белән яуга,
Кереп була сезнең белән гүргә.

Мин сагынып искә алачакмын
Сезнең белән үткән елларымны.
Мин тагын бер тапкыр үтәр идем
Сезнең белән үткән юлларымны.

Мин дә төшеп калганнардан түгел,
Мин шулай ук әллә кем дә түгел.
Сездән артык җирем булмаса да,
Мин, әлбәттә, сездән ким дә түгел.

Белеп яшим мин үз дәрәҗәмне,
Яхшы beләм мин үз урынымны.
Мин юкка да борын салындырмыйм
Һәм күтәрмим юкка борынымны.

Егетлекләр эшләштерсәм дә мин,
Беркемгә дә этлек эшләмәдем.
Беркемгә дә өреп калганым юк,
Беркемне дә юкка тешләмәдем.

Ә үземә өрүчеләр булды,
Мин аларга юри эндәшмәдем.
Миннән талантлылар, батырлар бар —
Мин алардан бер дә көнләшмәдем.

Кичерерсез мине, кирәк чакта
Сезнең төсле әгәр булалмасам,
Кешеләргә сез эшләгән кадәр
Игелекләр әгәр кылалмасам.

Сезнең белән мин ярышмыйм — сезне
Тырышсаң да узып булмас иде...
Ә шулай да сезнең үзегезгә
Миннән башка кызык булмас иде.

Мин, әлбәттә, сезнең кебек түгел —
Үзгәралмыйм, үзем аңласам да.
Сезнең янда мин чәүкә дә түгел,
Күгәрчен үк була алмасам да.

Курыкмагыз, мин таракан булып
Беркайчан да төшмәм ашыгызга.
Киртә булып ятмам юлыгызга,
Кайгы булып килмәм башыгызга.

Сезгә күбрәк шатлык китерермен,
Мин тоз салмам сезнең ярагызга...
Рәхмәтле мин сезнең һәммәгезгә,
Алган өчен мине арагызга.

Мин яратам сезне, чордашларым!
Сез кадерле миңа барыгыз да!
Шуңа күрә дә мин сезнең белән,
Шуңа да мин сезнең яныгызда!

*29.10.03*

## *Күпме шигырь яздым...*

Сиңа, әнкәй, мин шигырьләр яздым,
Сиңа атап җырлар чыгардым.
Сиңа багышланган җырлар белән
Мин халкымның җанын сугардым.

Сиңа багышланган җырларымны
Бөтен татар халкы тыңлады.
Тыңлады да татар, җырлады да...
Юк аларның әл дә тынганы.

Минем җырларымны җылый-җылый
Җырладылар бөек җырчылар.
Алар әйтә иде: «Әнкәеңә
Син тагын бер яңа җыр чыгар!»

Беләм, беләм: ул булырга тиеш
Татарымның гаме, иманы...
Тик андый җыр язылмаган әле,
Язалмам да инде мин аны.

Бик язасым килә...
Булдыралмыйм...
Йөрим шуңа башны иебрәк.
Син җырлардан, әнкәй, әйбәтрәк шул,
Шигырьләрдән син бит бөегрәк!

*11.04.03*

## *Минме?*

Күкрәгемдә гомер буе
Минме сөю йөртмәгән?..
Моннан соң да йөртәчәкмен —
Дәрт әле дә бетмәгән!

Янып-пешеп, тиргә төшеп
Минме икмәк икмәгән?..
Моннан соң да игәчәкмен —
Әле тир дә кипмәгән!

Үземнең туган халкыма
Минме хезмәт итмәгән?..
Моннан соң да итәчәкмен —
Ялга вакыт җитмәгән.

Шау-гөр килеп, янып-көеп
Минме гомер итмәгән?..
Моннан соң да итәчәкмен —
Гомер әле үтмәгән!

*4.11.03*

## *Беләм мин үзем генә...*

Ничә көн инде докторлар
Тикшерә йөрәгемне.
Тыңлыйлар, тын алдыралар —
Бирәләр кирәгемне!

Тегеләй итеп карыйлар,
Болай итеп карыйлар.
Даруын да эчерәләр,
Уколын да кадыйлар.

Көн саен кардиограмма,
Көн саен УЗИ карый.
Ә мин тыныч кына ятам:
Карагыз, ярый, ярый.

Барысы да әйбәт, диләр,
Барысы да урында.
Докторлар белә барсын да
Минем йөрәк турында.

Әллә чынлап та аңлыйлар,
Әллә инде алдыйлар...
Юк, йөрәкнең ник янганын
Алар белә алмыйлар.

Бирсен инде докторларга
Сабырлык, түзем генә...
Ә йөрәкнең ник янганын
Беләм мин үзем генә.

*8.10.03*

## *Көзгә керүләре авыр...*

Көзгә керүләре авыр...
Аннан күнегәсең.
Бөтен җаның-тәнең белән
Көзгә күмеләсең.

Ә көз озын, ә көз озак...
Мәңге үтмәс кебек.
Күңелдәге бу сагышлар
Мәңге бетмәс кебек.

Көзгә керүләре авыр...
Керсәм, чыгар идем.
Көзгә түзсәм, мин ничек тә
Кышка чыдар идем.

Рәхәт кышка күчүләре,
Әгәр күчә алсаң...
Ә нишләрсең, шушы ачы
Көздә торып калсаң?!

*13.10.03*

## *Сиңа бик кыен булгандыр...*

*Хәйдәр Бигичевка*

И моң иде күзләреңдә,
Моң иде карашыңда...
Сиңа бик кыен булгандыр
Моңсызлар арасында.

Моңсыз да булдымы кеше?!
Басты безне моңсызлар...
Синең моңнан безнең әле
Күңелебез мең сызлар.

Сызлансаң да, моңлансаң да
Туры килә таманга —
Моңлы булулар авыр шул
Мондый моңсыз заманда.

Кемгә кирәк синдәге моң,
Кемгә кирәк тавышың,
Кем ишетсен синең моңлы
Йөрәгеңнең кагышын.

Ул чаклы ачы моңнарга
Чыдыйдыр сирәк йөрәк.
Моңсызлар бәхетлерәктер,
Моңсызлар кирәклерәк...

Киттең инде күңелләрне
Моңнар белән сугарып.
Үзең киткәч, моңсызлар да
Калдылар моңсуланып.

Калды җаннар боегышып,
Калды дөнья моңланып.
Язам менә... каләмемне
Синең моңнарга манып.

*3.05.99*

### *Уйландыра икән...*

Китереп кысса йөрәгең,
Уйландыра икән...

Йөрәгеңне уеп-уеп
Уй яндыра икән...

Сискәндерә, тетрәндерә,
Уяндыра икән...

Авыртынып ятулары
Оялдыра икән...

Бераз гына хәл керсә дә
Куандыра икән...

Кайчагында йөрәк шулай
Кыландыра икән...

*20.10.03*

## *Сак-Соклар без...*

Инде күптән Сак-Соклар без...
Түзәрлекләр калмады.
Кемнәр безне аерды соң?
Кемнәр безне каргады?

Татарларым-газизләрем —
И Сокларым-Сакларым...
Сагынам мин барыгызның
Бергә булган чакларын...

Без һаман табышмыйбыз шул,
Без һаман кавышмыйбыз.
Язмыш, дибез... Без шул инде
Язмышка карышмыйбыз.

Сак-Сок, Сак-Сок...
Төште безгә
Кемнәрнең каргышлары?
Кемнәрнең хаталары без,
Кемнәрнең ялгышлары?

И Сакларым, и Сокларым!
Сак та Сок та Сак та Сок...
Күңелемнең ишекләрен
Кемнәр кага шак та шок?

Сак та Сок без,
Сак та Сок...

*02.11.03*

## *Уфадагы дусларым*

Уфа, дим дә, уф, дип куям,
Уфа, дим дә уфтанам.
Гомер буе Уфадагы
Дусларыма укталам...

Мин бу соңгы араларда
Бигрәк әллә нишләдем:
Сагындыра якташларым,
Иптәшләрем, ишләрем!

Дусларым — Сафуаннарым,
Рәмил, Рәмисләрем...
Әй шәп егетләр дә инде —
Китәрлек тә исләрең!

Фаилләрем, Рәдифләрем,
Рудоль, Марат, Римнәрем...
Тоям авыр чакларымда
Мин аларның иңнәрен!

Кәдим, Айдар, Идрис, Урал...
Тагын әллә кемнәрем!
Алар минем кардәшләрем,
Алар минем тиңнәрем!..

Бар бит әле Мостай төсле
Бик газиз абыйларым!
Ни кызганыч, бик аз калды,
Аз калды андыйларым.

Дуслар иде Вазыйх, Динис,
Нәҗар, Атнабайларым...
Булган бит әй Уфаларда
И нинди агайларым?!

Калдылар чордаш дусларым —
Таяныр терәкләрем!
(Дусларыма үземнең дә
Бар микән кирәкләрем?)

Уфада минем дусларым
Ким дигәндә мең, димен!
Бу шигырьне кайсысына
Арнарга да белмимен...

Сагынам сезне, дусларым,
Сагынам сине, Уфам, —
Сагынган төсле Еники,
Сагынган төсле Туфан!

Нинди сагынудыр инде
Бөрөзлексез, туктаусыз...
Үзем дә белмим, ничекләр
Яшимдер мин Уфасыз?!

*29.11.03*

## *Хатын-кыз ямьсез булалмый*

Хатын-кыз ямьсез булалмый,
Хатын-кыз чибәр була!
Шуны күрмәгән ир-ат ул,
Әлбәттә, җүләр була.

Хатын-кыз ямьсез булалмый,
Юньсезе булыштыра...
Кайчакта чип-чибәрләр дә
Күңелне кырыштыра.

Хатын-кыз ямьсез булалмый —
Күрә белергә кирәк.
Хатын-кызның күңеленә
Керә белергә кирәк!

Хатын-кыз ямьсез булалмый —
Ул шулай яратылган...
Күпмесенә сокланылган,
Күпмесе яратылган!

Хатын-кыз ямьсез булалмый!
Яратсаң, ул нурлана!
Болай да матур хатын-кыз
Тагын да матурлана!

Хатын-кыз ямьсез булалмый —
Хатын-кыз матур, матур!
Хатын-кызны моннан соң да
Ир-атлар матурлатыр!

Хатын-кыз ямьсез булалмый
Яратылса, яратса...
Шул хатын-кыз — кичләр җитсә,
Шул хатын-кыз — таң атса!

*23.11.03*

## *Остазларым*

Авылымда һаман өч-дүрт урам,
Авылымда һаман шул ук йөз өй...
Күрергә дип кайтты остазларым —
Гариф Ахун белән Шәүкәт Гали
Һәм, әлбәттә инде, Илдар Юзи.

Авылымда шулкадәр дә рәхәт,
Бар да ихлас монда, бар да гади.
Якташларымнан да гади икән
Илдар Юзи белән Гариф Ахун
Һәм, әлбәттә инде, Шәүкәт Гали.

Нигеземдә шигъри догаларын
Укыдылар... юлым булыр ак, уң.
Ул доганы кемнәр укыды бит?! —
Шәүкәт Гали белән Илдар Юзи
Һәм, әлбәттә инде, Гариф Ахун.

Бер карасаң, алар — аксакаллар,
Бер караган чакта, алар — сабый...
Кемнәр булсын инде, остазларым —
Шәүкәт Гали белән Гариф Ахун
Һәм, әлбәттә инде, Илдар абый.

*01. 06. 99*

## *Юка иңнәреңнән кочам да...*

Мин бер сиңа карыйм, бер үземә...
Без бит элекке дә, түгел дә.
Ни булса да яратабыз әле
Бер-беребезне без бүген дә.

Яшь чактагы кебек дөрли-дөрли
Әле һаман яна ич йөрәк.
Картаясы килми — киресенчә,
Яратасы килә көчлерәк!

Гашыйклар ул картаймаска тиеш...
Йөрәк аңлый, акыл аңламый.
Мин кайсына булырга да белмим —
Кайсы алдый, кайсы алдамый?

Үксез сабый төсле үксим кайчак,
Юка иңнәреңнән кочам да...
Күз яшьләрең белән битне юам,
Үз яшьләрем белән кушам да.

Ә картлык ул килми, килми әле —
Без белмибез аны бар дип тә.
Күңел генә никтер бик еш тула...
Болай үзе бар да тәртиптә.

*9.11.03*

## *Манзара*

Көзнең соңгы ае килде —
Ноябрьнең бере.
Бүген шундый кояшлы көн!
Кояш шундый эре!

Нәкъ җәй айлары шикелле —
Көне көләч, җылы.
Бөтен дөнья тынып калган,
Тынган кошлар җыры.

Кайсы якка карасаң да —
Бер яфраксыз агач.
Сәер — агачлар бик иртә
Бер яфраксыз калгач...

Әллә агачлар саташкан,
Әллә көз ялгышкан...
Көзге кояш нурларына
Пәрәвез ябышкан.

Без барыбер кар салкынын,
Кыш киләсен тойдык:
Юл читендә беркөн яуган
Карлар уйдык-уйдык...

Җәй дә, көз дә, кыш та бүген!
Никтер җил дә исми...
Бу табигать кайчагында
Әллә ниләр эшли.

*01.11.03*

## *Еникине дә озаттык...*

*Әмирхан ага Еникине юксынып*

Еникине дә озаттык...
Дөньялар бушап калды.
Кояшлы көннәребез дә
Төннәргә охшап калды.

Еникине дә озаттык...
Ә нинди көчле иде!
Арабыздан бик тиз генә
Ул китмәс төсле иде.

Еникине дә озаттык...
Күңелсез, моңсу, читен.
Китеп алып китте кебек
Күңелләрнең бер читен.

Көтелмәгән югалтуга
Дөнья шул бай икән ул.
Еникине дә озаттык...
Дөнья шулай икән ул.

*2000*

## *И әнкәем — сыңар канат...*

И әнкәем — сыңар канат...
Сабыр канат — бәгырьләрем
Телгәләнә сиңа карап!
Сыңар канат...

И әнкәем — сыңар канат...
Җил иссә дә каерылыр,
Җил иссә дә сынар канат!
Сыңар канат...

И әнкәем — сыңар канат...
Кирәк булса, безне яклап
Алышка да чыгар канат!
Сыңар канат...

И әнкәем — сыңар канат...
Безне яклап, безне саклап
Беткәндер ул канат... канап!
Сыңар канат...

И әнкәем — сыңар канат...
Безнең хакка барсына да,
Барсына да чыдар канат!
Сыңар канат...

И әнкәем — сыңар канат...
Сыңар канат асларында
Үсәр идем кабат-кабат!
Сыңар канат...

*11.01.03*

## *Шигырьне мин үзем язмыйм*

Шигырьне мин үзем язмыйм,
Кемдер әйтеп яздыра.
Колакка шигырь пышылдап,
Мине юлдан яздыра.

Миңа кемдер әйтеп тора,
Мин язып кына барам.
Тик язып өлгерә алмыйм
Яисә бетә карам.

Ул иң әйбәт шигырьләрен
Әйтеп тора кич-иртән.
Ләкин язып ала алмыйм —
Мин бик начар ишетәм.

Колагыма пышылдаучы
Ходай түгелдер, димен.
Ходай әйтеп торса, күптән
Мин Тукай булыр идем.

*10.10.03*

## *Яфрак туе*

Яфракларның бәйсез чагы,
Яфракларның туе.
Очу гына, качу гына
Аларның бар уе.

Өзелә дә оча алар,
Өзелә дә оча,
Бер-бер артлы тезелә дә,
Тезелә дә оча.

Үзләре үк кош бит алар,
Үзләре үк канат...
Җиргә бер кунгачтын, алар
Очалмаслар кабат.

Алар бер кат кына оча,
Бары бер мәртәбә.
Бер булса да оча алу —
Үзе бер мәртәбә!

*04.11.03*

## *Без яшьлектән килгән ике хат*

Сабый төсле ихлас чакны күңел
Торган саен ныграк сагына.
Казаннардан хатлар кошлар булып
Оча иде Бөре ягына.

Ә Агыйдел буйларыннан очып
Килә иде синең хатларың.
Истә әле һаман каушый-каушый
Хатларыңны ачкан чакларым.

Ул хатларда без сөйдек тә, җаным,
Без көйдек тә анда, яндык та.
Ә ул хатлар сакланадыр әле
Берәр ящиктә йә сандыкта...

Шул вакытлар шундый сагындыра,
Искә алсам, китә исләрем.
Тик укырга куркам ул хатларны —
Яшьлектәге сөю хисләрен.

Без кагылмыйк, әйдә, ул хатларга,
Калсын алар безнең яшьлектә.
Саклансыннар хисләр күңелләрдә,
Саклансыннар хатлар ящиктә.

Кабатланмый тарих кабат-кабат,
Кабатланмый яшьлек ике кат...
Ә хатларга тимик! Без үзебез
Шул яшьлектән килгән ике хат!..

*25.10.03*

## *Бер Бөркет бар Уралда*

*Мостай Кәримгә*

Бер Бөркет бар Уралда —
Берәү генә ул анда!..

Карап торсаң, гаҗәеп —
Уйный җил, уйный давыл,
Җибәрсә канат җәеп!

Канатлары — колачлы!
Карашлары — кояшлы!

Ул һаман күтәрелә
Чал Урал күкрәгенә,
Ул һаман күтәрелә
Чал Урал күкләренә!

Язмышы аның — башка...
Биектә, кыя ташта!
Кояшның ал нурлары
Аңа төшә иң башта.

Кала ул кайчакларда
Кара болыт эчендә...
Ә оясы — кыяның
Иң куркыныч төшендә.

Кыя күккә терәлгән...
Бөркетнең карт карашы
Чиксезлеккә төбәлгән.

Аста — Җир, өстә — Галәм...
Урал күгендә Бөркет
Җилферди, гүя әләм.

Бөркеттә күпме куәт,
Күпме сер яшеренгән!
Уйлап куям: без дә бит
Шул Бөркет Нәселеннән...

Бер Бөркет бар Уралда —
Берәү генә ул анда!

*2001*

### *Чиләбе*

Үкенмәс идем үлсәм дә,
Чиләбене бер күрсәм,
Чиләбе чибәрләренең
Кочагына бер керсәм...

Чиләбене күрдем инде,
Килми ләкин үләсем.
Күргәч шушы матурлыкны,
Кем үләргә теләсен?!

Яшәр татар, җир йөзендә
Чиләбе бар чагында.
Ул үзе дә сүнмәс бер җыр
Татарымның җанында...

Күрдем инде Чиләбене,
Үкенечкә калмады.
Чибәрләре генә минә
Берсе дә күз салмады.

Чиләбегә яшьрәк чакта
Киләсе калган икән...
Тик барыбер Чиләбегә
Мин гашыйк булып китәм!..

Пешеп торсын җиләкләрең,
Тулып торсын чиләгең!
Читтә түгел син татардан,
Чит түгел син, Чиләбем!

*12.09.02*

## *Гарәп илендә*

Кала булган ком чүлләре,
Бакча булган барханнар...
Рәхәт чигәләр шушында
Бар шәехләр, бар ханнар.

Югыйсә безнең шикелле
Мөселман-адәмиләр.
Бүгенге ул бай шәехләр —
Кичәге бәдәвиләр.

Чүл өстендә — чын могҗиза,
Чүл өстендә — әкият...
Күңелләрендә булгандыр
Ак әкият — ак ният!

Мәңге дә ышанмас идем,
Үзем барып күрмәсәм,
Ул әкият ишекләрен
Үзем ачып кермәсәм.

Бик тырышсаң, була икән
Җир өстендә дә җәннәт...
Ни өчендер куйдым шунда
Үз-үзебезне жәлләп.

Ә безнең тормыш инде ул
Ни тәмуг бит, ни җәннәт...

Менә шулай, җәмәгать!

*8.11.03*

## *Син һаман сер*

*Кларага*

Гомер буе сине сөйдем...
Син һаман сер, син — тылсым.
Син бит миңа, миңа гына
Насыйп булгансың...
Булсын!

Димәк, Ходай үзе кушкан,
Үзе шулай теләгән:
Сине — миңа, мине — сиңа,
Сиңа гына тиңләгән!

Синнән дә матурларны мин
Тапмадым, табалмадым.
Дөресрәге, мин аларны
Эзләп тә карамадым.

Һәркемнең үз матуры бит,
Һәркемнең үз гүзәле.
Синең гүзәллегеңә дә
Йөрәк көчкә түзәле!

Кайчак сөю давыллары
Алсалар да бөтереп,
Дөньяның бар матурларын
Булмый сөеп бетереп.

Матурлар ул меңләгән дә,
Миндә мең йөрәк түгел.

Миңа, җаным, синнән башка
Беркем дә кирәк түгел!

Минем кебекләр, әлбәттә,
Һәркемгә дә эләкми...
Хәер, мин дә синнән башка
Беркемгә дә кирәкми.

*18.11.02*

## *Гомер Сабантуе*

Гөрләп тора гомер Сабантуе...
Биргән Ходай көннең чуакларын.

Тиздән урак өсте. Авылдашлар
Көйләп куйган инде ураkларын.

Челтер-челтер әле чишмәләрем,
Тулып ага әле улакларым.

Авылымның саф суларын эчсәм,
Юыладыр кебек гөнаһларым.

Инеш булган инде чишмәләрем,
Урман булган инде куакларым.

Мине күргәч, елап җибәрделәр —
И талларым минем, елакларым...

Ә авылым, Сабантуйга диеп,
Якыннарын җыйган, еракларын.

Алар арасында Казаннардан,
Уфалардан килгән кунакларым.

Бар мир белән и телиләр миңа
Бәхет-шатлыкларның гел акларын.

Котлаулардан һәм дә мактаулардан
Чыңлап тора минем колакларым.

Тик шунысы гына... Тәгәри бит,
Сүтелә бит гомер йомгакларым...

Бүген исә гомер Сабантуе...
Искә алмыйк әле ул якларын.

*14.06.99*

## *Күзләр белән бергә*

Көз килгән Сөн буйларына —
Җәйне алыштырып.
Шулай инде...
Табигатьне
Булмый ялгыштырып.

Үземнең Сөн буйларымны
Йөрим караштырып...
Сөндә уйный көзге кояш,
Күзне камаштырып.

Сөн буйлары җитдиләнгән,
Яшеллеген җуйган —
Җиде төрле төс җитмешкә
Әйләнгән дә куйган.

Сөн буе кайдан җыйгандыр
Бу кадәрле төсне! —
Бу бит Фаил Зыязовның
Пейзажлары төсле.

Кайттым мин дә Сөн буена
Көзләр белән бергә.
Көзләр белән бергә китәм,
Көзләр белән генә...

Сөн буйлары шулкадәр дә
Балкып торыр икән! —
Миннән соң да мәңге шулай
Матур булыр микән?

*7.10.03*

## Әнкәйне сайлап алмыйлар

Әнкәсен, бик теләсә дә,
Сайлап алалмый кеше.
Әнкәйләрне Ходай бирә,
Ул фәкать Ходай эше!

Әнкәй ул чит-ят булалмый, —
Газиз генә булала!
Безнең өчен ул — Илаһи,
Безнең өчен ул — Алла!

Әнкәй ул гади булалмый, —
Гүзәл генә булала!
Әнкәеңә мәхәббәтле,
Мәрхәмәтле бул, Бала!

Әнкәй күңеле, һай, сизгер —
Барсын да белә бит ул...
Әнкәйне сайлап алмыйлар —
Бердәнбер генә бит ул!

*21.01.03*

## Үзебез!

Бөекләр китеп беткәннәр...
Алмашка килүчеләр
Бик күренми әле, гәрчә
Җитәрлек теләүчеләр.

Шуңа күрә ил алдында,
Пакь калсын дип йөзебез,
Бөекләрнең вазыйфасын
Башкарабыз үзебез!

*9.11.03*

## Мин борчылып яткан булам

Мин борчылып яткан булам,
Төрле уй килә башка:
Янәсе, мин монда чакта
Нишләрләр миннән башка?!

Мин борчылып яткан булам,
Тик җан юкка көенә.
Дөньяның китми исе дә —
Тәгәри үз көенә.

Мин борчылып яткан булам:
Кәеф тә юк, хәл дә юк.
Ә тормыш кайный минсез дә —
Әллә бар мин, әллә юк.

*21.10.03*

### *Сәйдәш. «Шәрык биюе»*

Күзәнәкләр аша җанга аша,
Канга таша шәрык моңнары.
Юк, ул моңнар еракта гы түгел —
Күңелдәге, минә мондагы.

Татарларның ерак тарихлары
Шушы моңга, көйгә әйләнгән —
Бәгырьләргә кагылган бер чөйгә,
Йөрәктәге җөйгә әйләнгән.

Гасырлардан килгән хәтер ул моң,
Безнең хәтер, татар хәтере.
Ә хәтер ул безнең каныбызда,
Җаныбызда әле дә тере!

Әйдә, кушыл шәрык биюенә —
Ни тере без юкса, ни үле...
Кем туктатсын гасырлардан килгән
Бөек моңны, бөек биюне?!

Әллә үлем, әллә туй биюе —
Бии ханнар, падишаһлар да!
Бер-бер артлы оча ханнар башы,
Оча тора гади башлар да.

Далалардан тарих узып бара —
Кылыч чыңлый, уклар сызгыра.
Бабайларның кайсылары анда
Гасыр тузаннарын туздыра?!

Ишетелә тояк тавышлары,
Ыңгыраша дала... ярадан.
Далалардан килгән моңлы оран
Якынлаша безгә яңадан.

Шәрык моңы һаман якыная...
Әй ачысы аның, әй тәме!..
Урта гасырларда яздыңмы син
Бу биюне, Сәйдәш, әйт әле!

*12.10.03*

## *Өйрәнеп кенә киләм...*

Бер күрсәм дә гашыйк булдым,
Мең күрсәм дә туймадым.
Җаным-тәнем белән сөйдем —
Хисләремне тыймадым.

Тыйган чаклар да булгандыр —
Мин аларын тоймадым.
Мәҗнүн кебек, Таһир кебек
Яратам дип уйладым.

Тик мин әле ул чагында
Ярата белмәгәнмен:
Сине гөлгә күммәгәнмен,
Утларга кермәгәнмен.

Мин бит сине яратырга
Өйрәнеп кенә киләм.
Синең күңел кылларыңа
Көйләнеп кенә киләм.

Ярattыра беләсең син
Хәзер инде үзең дә...
Гомер булгач, күрдек менә
Мәхәббәтнең күзен дә.

*17.10.03*

## *Китәләрдер инде...*

Ак каеннар яфрак ташлады.
Вак яңгырлар ява башлады.

Явар төсле озак, иркенләп...
Китәләрдер инде төркемләп

Туган якның күчмә кошлары.
Кыш — аларның салкын дошманы.

Бәлки инде очканнардыр да...
Күренмиләр кошлар яңгырда.

*22.10.03*

## *Без Илештән чыгып киткән чакта*

*Рудоль Авсаховка*

Без, Илештән чыгып киткән чакта,
Малай-шалай гына булганбыз.
Җәйге челләләрдә чиләнгәнбез,
Кышкы салкыннарда туңганбыз.

Тормыш дигәннәре безгә бер дә
Кочакларын җәеп тормаган —
Безнең өчен беркем чәчмәгән дә
Безнең өчен беркем урмаган.

Мәскәүдә дә безне, Уфада да,
Казанда да беркем көтмәгән.
Аркабыздан беркем какмаган да
Артыбыздан беркем этмәгән.

Гомер буе чаптык — атлансак та
Атландык без җитез атларга.
Егылсак та кара коелмадык,
Сер бирмәдек җиде ятларга.

Кешеләрдә безнең эшебез юк,
Үз эшебезне без эшлибез.
Тимәсәләр, без дә кагылмыйбыз,
Кагылсалар, җебеп төшмибез.

Эшләп булмаса да безгә тигән,
Безгә дигән эшнең барсын да,

Йөзебез ак безнең ил алдында,
Күңелләр пакь Ходай каршында.

Тик тормышның тәмен белгәч кенә,
Чибәрләнгәч кенә кызлары,
Әйбәтләнгәч кенә дөньялары,
Сиздергәли гомер узганы.

Шулай да без матур яшәгәнбез,
Ә Илештә туып уңганбыз...
Без Илештән чыгып киткәндә үк
Шәп егетләр, ахры, булганбыз!

*2001*

## *Кеше гомерләре бигрәк кыска...*

Кеше гомерләре бигрәк кыска...
Ходай безгә, белмим, нигәдер
Кошлар гомере дә бирмәгән шул.
Яши белсәң, җитәр, дигәндер.

Кеше гомерләре бигрәк кыска...
Шунсына да шөкер итәбез.
Кыска гына шул бер гомернең дә
Кадерләрен белми китәбез.

Кеше гомерләре бигрәк кыска...
Кадерләрен бик тә белерлек.
Һәр сәгате аның санаулы бит,
Һәр сәгате үзе — гомерлек.

Кеше гомерләре бигрәк кыска...
Сизелми дә хәтта калына.
Әйтерсең лә гомер учаклары
Бер мизгелгә генә кабына.

Кеше гомерләре бигрәк кыска...
Бер сүнә дә кабат кабынмый.
Һәрберебезгә дә кагыла ул,
Шагыйрьләргә генә кагылмый.

*17.11.02*

## Татар

Татар белән изгән Рәсәй,
Татар белән баскан.
Татардан башка булалмый, —
Татар баштан ашкан!

Татар күчмә кошлар кебек —
Ул туктаусыз күчә.
Утлар-сулар кичә татар,
Шахталарга төшә.

Тату булып яши белә
Татар барсы белән:
Үрчетә чит милләтләрне
Татар башы белән!

Күпме милләт карап тора
Татар күзе белән,
Күпме милләт балкып тора
Татар йөзе белән!

Күпме милләт яшәп ята
Татар каны белән,
Үзе — үзбәк, урыс, башкорт...
Татар — җаны белән.

Татарларны үлчи алмый
Бернинди дә бизмән...
Татар белән баскан Рәсәй,
Татар белән изгән!

*13.11.03*

## *Чүплектәге шигырьләр*

Ачу килеп йөри иде
Өйдә чүп-чар күплеккә, —
Бөтенесен чыгардым да
Ташладым мин чүплеккә.

Әмма ләкин мин ташлаган
Чүп-чар белән бергәттән
Кайчандыр язып куелган
Шигырьләр дә эләккән.

Мин инде ул шигырьләрне
Яңабаштан язалмам.
Бер тапкыр янган утларда
Кабат-кабат яналмам.

Мин, билгеле, аптырашта,
Белмим нәрсә әйтергә? —
Ул шигырьләрнең берсе дә
Төшми минем хәтергә.

Ярар, алар, юньле булса,
Искә төшәрләр иде...
Укучылар гына менә,
Белмим, нишләрләр инде?

*1996*

### *Син бит мондый түгел идең...*

Әйтәм сиңа чын күңелдән,
Әйтәм сиңа чынын:
Чишендерсәң, кызлар кебек
Әле буең-сының.

Син чын ханбикә шикелле,
Шәпләп киендерсәң.
Сылуланыплар китәсең,
Шулай сөендерсәң.

Йөзләрең китә ачылып,
Кершән-фәлән сөртсәң,
Бит очыңа матур итеп
Берәр миң дә төртсәң.

Әгәр дә буяп җибәрсәң,
Чәчләрең дә кара —
Чәчләреңне яшь чактагы
Кебек итеп тара!

Син бит мондый түгел идең
Хәтта кыз чагында...
Син дип кабат янам инде
Сөю учагында!

*7.10.03*

## *Елатма инде Әнкәйне...*

*Зөһрә Сәхәбиевага*

Бик ярата сине Әнкәй,
Сиңа гел сәлам юллый...
Сине тыңлый да елый ул,
Сине тыңлый да елый.

Үзебез дә күп елаттык,
Елатасың инде син.
Син бит аның ниләр уйлап
Елаганын белмисең...

Кайгыдан күп елады ул,
Хәзер инде — шатлыктан.
Елап туйгач, сиңа рәхмәт
Укыйдыр ул актыктан.

Шәммәттә дә җырладың син,
Елаттың бар авылны.
Син җырлаган минутларда
Сөн моң булып агылды...

Әнкәй синең җырлавыңны
Төшерә искә һаман.
«Зөһрәгә син сәлам әйт, — ди, —
Яшәсен исән-аман!»

...Ул елый башлый Казаннан
«Әнкәй»не җырлатканда.
Елатма инде син аны,
Җиткән без елаткан да.

*7.11.98*

### Әверелеш

Тәрәзәдән көзне күзәтәмен,
Әллә инде көзне тизләтәмен?!

Үзгә бүген — җаным, үзгә — тәнем:
Җаным белән көзне үзгәртәмен.

Ә көз һаман китми — суза әле,
Йөрәк кенә никтер сыза әле.

Әле генә коры һава иде,
Инде менә яңгыр ява инде.

Бөтен дөнья үзгәрде дә куйды.
Табигать тә көз булудан туйды.

Ничек ышанмыйсың тылсым барга?! —
Әйләнде дә куйды яңгыр карга...

Беренче кар ява уйный-уйный,
Тик күңелем әле кышны тоймый...

Яңа карлар чагылдыра күзне...
Карап торам уйлый-уйлый көзне.

Йөрәгемнең кысылган бер чагы,
Көз һәм кышның кушылган бер чагы...

Тәрәзәдән күзәтәм мин тышны:
Көзне түгел инде — яңа кышны.

*22.10.03*

### *Күңелләр нечкәргәндә...*

И туган якның якынлыклары,
Басуларының алтынлыклары.

Туган ягымның моңсулыклары,
Тын сулыклары, уйсулыклары.

Сөн буйларының гүзәллекләре,
Үзәкләреңне өзәрлекләре.

Агымнарының и тизлекләре,
Дулкыннарының җитезлекләре,

Туган ягымның күркәмлекләре,
Яланнарының иркенлекләре.

Офыкларының алыслыклары,
Һәр түмгәгенең танышлыклары...

Якташларымның ябайлыклары,
Күңелләренең әй байлыклары...

И әнкәемнең сабырлыклары,
Идәннәренең сарылыклары,

И йөзләренең яктылыклары,
Ризыкларының татлылыклары...

И балачакның үксезлекләре,
Хыялларының чиксезлекләре...

И бу хәтернең истәлекләре,
И бу күңелнең нечкәлекләре...

*13.11.03*

## *Кычыту*

Телгә әллә ниләр килә —
Тел кычытып тора.
Бер кычытса ярар иде,
Гел кычытып тора!..

Иң асыл сүзләрен илһам
Гел очыртып тора.
Шигырь итеп язмый булмас —
Кул кычытып тора!..

*14.11.03*

## *Синең чәчләр әле кара иде*

*Фәрит Мөхәммәтшинга*

Синең чәчләр әле кара иде,
Күңелләрдә дәрман бар иде.
Татарстан Дәүләт Советының
Заллары да безгә тар иде.

Эшләдек без кулдан килгәнен дә,
Килмәгәннәрен дә эшләдек.
Кулдан килмәсә, без тешләшмәдек,
Иреннәрне генә тешләдек.

Кайнар заманның да, Казанның да
Син эченә кереп кайнадың,
Мәскәүнең дә көен көйләдең син,
Казанның да җаен җайладың.

Ә без исә янәшәңдә булдык,
Синең белән бергә атладык.
Акладыкмы халык ышанычын? —
Миңа калса, әйе, акладык.

Тик артыгын эшли алмас иде
Кем булса да безнең урында.
Ә чәчләргә чаллар төшкән икән,
Ансы гына аның ерунда!

Чыгармаслар җырлар без яшәгән,
Без эшләгән чорлар турында.
Безнең дәвер үзе җыр шикелле...
Без һәммәбез — тарих кулында.

Болай гына тормас дөньялары,
Килми калмас башка патшалар.
Кайтмый калмас безгә мөстәкыйльлек —
Ансын инде эшләр башкалар.

Тормыш дәвам итәр моннан соң да,
Безнең картаюга карамас...
Ул дәверләр генә кире кайтмас,
Синең чәчләр генә каралмас.

*25.10.03*

### *Яши алмыйм синсез...*

Күңелем ямьсез, суым тәмсез —
Синсез миңа кыен.
Җитми миңа синең җылың,
Җитми синең куен.

Мин сиңа бик тә мохтаҗмын,
Син миңа бик кирәк.
Синең кебекләр юктыр ул,
Булса да бик сирәк...

Дөньяда үз тиңең кирәк,
Яшәп булмый тиңсез.
Мин дә менә бер минут та
Яши алмыйм синсез.

Син белеп тор: икебезнең
Мәхәббәттән башка
Әйләнермен мин тимергә
Йә булмаса ташка.

Мин дә әүлия түгелдер,
Бардыр төрле ягым.
Тик сиңа бит таш кирәкми —
Ярат мине, җаным!

*18.10.03*

## *Тагын салкыннар башлана...*

Тагын салкыннар башлана...
Тагын шул урыс кышы —
Урысның шул озын кышы,
Корычтай кырыс кышы.

Тагын салкыннар башлана...
Үзәкне өзә торган,
Җилекләргә җитә торган,
Шулай да түзә торган.

Тагын салкыннар башлана...
Сизәм шәһәр халкыннан.
Өшеп-туңып үтте гомер,
Баш чыкмады салкыннан.

Тагын салкыннар башлана...
Кайчан гына яз иде.
Җиле салкын, иле салкын...
Ни язсаң да аз инде.

*15.10.03*

## *Герман күге — кара кайгы*

*Германия күгендә һәлак булган*
*Башкортстан балаларының*
*якты истәлегенә багышлыйм*

Герман күге кара бүген,
Герман күге — кара үлем.
Бер җыр китми күңелемнән,
Хәтерләтеп герман күген:

«Атландым атның биленә,
Киттем герман җиренә.
Герман җире — кара үлән,
Әллә кайтам, әллә үләм...»

И сабыйлар! Күз яшьләрен
Тыеп торам көчкә-көчкә.
Сезне күрермен шикелле —
Карарга да куркам өскә.

Очтыгыз... Очып киттегез...
Бәргәләнә бәгырьләрем.
Белмичә дә калдыгыз бит
Бу дөньяның кадерләрен.

Герман күге — кара кайгы,
Герман күге — сагыш кына.
Чын түгелдер бу һәлакәт —
Әйткәннәрдер ялгыш кына...

Герман күге — кара айлы...
Йолдызлар — сезнең җаныгыз.
Яктыгыз төшәр безгә дә —
Йолдызлар булып калыгыз!

Күктәге якты йолдызга
Әйләнүе тиздер инде...
Тагын күпме йолдыз артты —
Кайсылары сездер инде.

Герман күге — кара келәм,
Каелган ул кайгы белән.
Бер җыр китми күңелемнән —
Нигә китмәгәнен беләм:

«Атландым атның биленә,
Киттем герман җиренә.
Герман җире — кара үлән,
Әллә кайтам, әллә үләм...»

*4.11.03*

## *Өлгерербез!*

Кырын-кырын карыйбыз без
Күптән узган заманнарга.
Ни өчендер яратабыз
Узганнарны яманларга.

Яманлыйбыз үзебезнең
Җанга якын үткәннәрне.
Димәк ки, яшь чагыбызны,
Кочканнарны-үпкәннәрне.

Нинди генә булса да ул —
Үзебезнең гомеребез.
Яшик әле!
Яманларга
Без кайчан да өлгерербез.

*4.11.03*

* * *

Тормыш булсын өчен
Галәм кирәк.
Галәм буш булалмый —
Гавам кирәк.

Гавам булсын өчен
Җир дә кирәк,
Һәр кешегә Туган
Ил дә кирәк.

Туар өчен туган
Өй дә кирәк.
Туган өйдә туган
Көй дә кирәк.

Иң мөһиме, җылы
Кочак кирәк —
Галәмдәге шул бер
Учак кирәк!

*20.11.02*

## *Сәхнә*

*Татарстанның халык артисткасы*
*Рузия Мотыйгуллинага*

Ачык сәхнә. Асыл бер зат!
Кем аңлар аның җанын? —
Бәхете дә, тәхете дә
Шушы сәхнә бит аның.

Ничә тормыш, ничә язмыш
Узган аның җаныннан?!
Йөрәкләре ничә янган,
Ничә тапкыр ярылган?!

Сәхнәләрдә ничә туып,
Ничә кат яшәгәндер?!
Мең кабат картайгандыр ул,
Мең кабат яшәргәндер...

Мәхәббәт хисләрендә дә
Мең кабат исергәндер,
Без кичергәнне берүзе
Мең кабат кичергәндер...

Кеше язмышлары белән
Яшәүләр авырдыр ул —
Кайгылары гомерлеккә
Йөрәктә калырдыр ул...

Ә үзе һаман үзгәрми,
Гүзәллек көчле шул ул —

Ничә кеше гомерләрен
Яшәгән кеше шул ул!

Бер карасаң — шау чәчәк ул,
Бер карасаң — көл-күмер...
Ничә гомергә торадыр
Сәхнәдә үткән гомер?..

Сәхнә — биек
Һәм мәңгелек!
Сәхнәдә ут кабына...
Ачыла да ябыла ул,
Ачыла да ябыла...

*4.03.2000*

### *Син әле дә матур...*

«Яшь чагымда мин дә матур
Булганмын икән!» — дисең.
Шулай булырга тиеш ул —
Юкка китмәсен исең.

Син әле дә бик матур бит —
Елмаеп кал, көлеп кал!
Бу көннәрең кире кайтмас —
Кадереңне белеп кал!

Алтмышта да әйтәчәксең:
«Бигрәк сулганмын икән...
Мин әле илле яшьтә дә
Матур булганмын икән!»

*13.10.03*

### *Биләр*

Биләрдә уйный көзге җил,
Зыңлый көзге көйләр.
Тирә-юньне элек монда
Биләгәндер Биләр...

Монда болгар батырлары
Алышкандыр билләр.
Тамашаны карагандыр
Падишаһлар, биләр.

Булгандыр алар акыллы
Йә булгандыр юләр...
Кайнагандыр монда тормыш,
Кайнагандыр Биләр!

Ташка калган таш калалар,
Җырга калган илләр...
Булмагандыр да шикелле
Бөек Шәһре Биләр.

Татарны тарих иләге
Тагын күпме иләр?
Иләнгән дә, игәлгән дә,
Имгәнгән дә Биләр...

Борынгы чал җилләр генә
Уйный синдә, Биләр...
Көтә безне нинди җилләр,
Дәшә безне ниләр,
Биләр?..

*10.03.99*

## *Әнкәең бигрәк ягымлы*

*Галимҗан Гыйльманга*

Әнкәең бигрәк ягымлы —
Гөл тама йөзләреннән.
Якты йөзле, татлы телле —
Бал тама сүзләреннән.

Әнкәең бигрәк кунакчыл —
Сые тезелеп тора.
Кайтып керсәң, ул бит сез дип,
Без дип өзелеп тора.

Әнкәең бигрәк сөйкемле,
Бигрәкләр ачык икән...
Бер сүз белән генә әйтсәң,
Мировой карчык икән!

Ул синнән күзен дә алмый,
Шулкадәр сөеп карый —
Сөйкемле итеп карый ул,
Сөеп-сөенеп карый.

Һәрбер ана үз баласын
Гел шулай назлый микән?..
Әнкәең матур җырлыйдыр,
Шигырь дә язмый микән?

Әнкәең шагыйрь җан икән,
Әнкәең и гади җан...
Менә кемнән икән синең
Шагыйрьлегең, Галимҗан!

*7.05.04*

### *Шаяру*

Шигырьләр яздым шаяртып
Йөрәк турында,
Шаяртып кына уйнадым
Йөрәк кылында.

Тик йөрәгем туктап алды
Шаяртып кына —
Әллә яратмыйча, әллә
Яратып кына.

Шаяруларның калмады
Миндә эзе дә...
Шаян булып чыкты әле
Йөрәк үзе дә.

*6.10.03*

## *Җәй хатирәсе*

Кышын абзар түбәсенә
Бар микән менгәнегез?
Печән безнең ястыгыбыз,
Ул безнең мендәребез.

Монда җәйнең үткәннәре,
Җәйнең киләчәкләре:
Шул килеш җиләкләре дә,
Шул килеш чәчәкләре.

Хәтта сандугачлары да
Сайрап җибәрер сыман...
Абзар түбәсенә җәйнең
Бөтен хуш исе сыйган.

Кайткан саен рәхәтләнәм,
Кайткан саен исерәм —
Җәйнең хатирәләреннән,
Кышкы печән исеннән.

Адашып калган монда җәй —
Печәне дә печәне!..
Йә, ничек, печән өсләре,
Җәйләр искә төшәме?

*8.11.03*

## Күз тимәсен сиңа, Мостай!

Сиксәннең син аръягында.
Килгән синең бар ягың да:
Мәхәббәт, акыл уты да,
Җыр уты да бар җанында...
Күз тимәсен сиңа, Мостай!

Син бит түгел башкорт кына,
Түгел татар гына да син!
Хакларын һәм нахакларын
Күп ишеттең шуңа да син...
Сүз тимәсен сиңа, Мостай!

Озын-озак — гомерләрең,
Алда да — гомер үрләрең.
Сүндерми тот гомереңнең
Көзге кызу күмерләрен...
Көз тимәсен сиңа, Мостай!

*8.11.02*

### *Яңа ел тосты*

Тагын бер ел гомер иттек —
Тагын бер ел үтте.
Озын булыр кебек иде —
Сүтелде дә бетте.

Шул бер елда игелекләр
Күпме кылганбыздыр?
Ниләр эшләгәнбездер дә
Ниләр кырганбыздыр?

Дөнья безне утларга да,
Суларга да салды.
Тау кадәрле эш эшләнде,
Тау кадәре — калды.

Иске еллар истәлеккә
Артта кала бара.
Гомерләр генә ел саен
Гел кыскара бара.

Тик гомерләр кыскара дип
Ятыйкмыни елап?
Соңгы Яңа елыбызга
Ерак әле, ерак!

Тагын ничә ел язгандыр? —
Ходай белә ансын.
Язганнары килә торсын,
Искеләре — калсын.

Биргәненә шөкер итик,
Һәм кадерен белик!
Беребезгә беребез тик
Куанычлар телик!

Моннан соң да бергә-бергә
Гомер итик гөрләп!..
Мин сезгә дип тост күтәрәм!
Һәм күрсәтәм үрнәк!

*30.12.01*

## *Җырладың син «Каһым түрә»не*

*Кадим Аралбайга*

Син касәңне тотып җыр башладың...
Без тыңладык сине кинәнеп.
Сөн буйлары китте иркенәеп,
Күз аллары китте киңәеп.

Борынгы моң ничек чыга диген
Юка гына шушы гәүдәдән.
(Кая инде безгә, шагыйрьләргә,
Алып Батырга хас дәү бәдән?)

Ә җыр ага, нәкъ Сөн кебек ага,
Үзе ят та, үз дә, таныш та.
Әй Аралбай, әй борынгы башкорт,
Күпме моңдыр синең тавышта?

Башкорт моңнарының кайнарлыгы
Күңелләрне алды пешереп.
Хан тавы да баш калкытып куйды,
Тарихнымы искә төшереп?

Илеш кенә түгел, Актаныш та
Тынып калды башкорт моңыннан.
Чакыру дип белеп, япь-яшь колын
Чабып килеп җитте болыннан.

Сөн буеның карт бер бөркете дә
Туктап калды очкан җиреннән.
Хәтта Сөн дә дулкынланып алды
Шул бөркетнең канат җиленнән.

Ә аннары бер мизгелгә генә
Агуыннан туктап тыңлады.
Үзең җырлап бетергәннән соң да
Синең җырың озак тынмады.

Җырың дәвам итте... Шуңа күрә
Кул чабарга хәтта кыймадык.
Моңнарыңны бүлдерербез диеп,
Өлгерербез диеп уйладык.

Татар белән башкорт өнсез калып
Тыңладылар сине, күр әле...
Сөн буенда, Шәммәт тау башында
Җырладың син «Каһым түрә»не.

*1999*

## *Шагыйрьләрнең газиз аналары*

Шагыйрьләрнең газиз аналары,
Нишләр иде Шигырь сездән башка?
Шигырь туа алыр иде микән
Сез өйрәткән Бөек Сүздән башка?

Сездән иңә илаһилык нуры,
Сездән килә шигырь ялкыннары.
Сезнең күңелегез аша уза
Шигърияттнең җәүһәр-алтыннары.

Сездән күчкән моңны түкми-чәчми
Шигырь итә шагыйрь улларыгыз.
Үзегез дә шагыйрь затлар бит сез,
Каләм тотмаса да кулларыгыз.

Нинди уллар бүләк иткәнсез бит
Шигърияткә — Шигырь Иләнә сез!
Үзегез дә җырга лаеклы сез,
Үзегез дә җырга әйләнәсез!

Сез күптәннән шигырь, җыр һәм дастан,
Җаныгызда — шагыйрь яралары...
Шигърияттнең үзе шикелле үк
Илаһи сез, Шагыйрь Аналары!

*2002*

## *Бүленмәсен төшләрең*

Сып-сылу булып йоклыйсың
Син үз-үзеңне кочып,
Яп-ялангач тезләреңне
Күкрәкләреңә кысып.

Тып-тын гына тын аласың,
Син нәкъ песи баласы.
Шул чагында чәчләреңнән
Килә сыйпап аласы.

Йөзеңдә нурлар уйнаклый,
Алсуланган бит уртаң.
Бер үбеп алыр идем дә...
Уятырмын дип куркам.

Тып-тын торам...
Чак-чак кына
Ачык калган түшләрең.
Мине күреп ятасыңдыр,
Бүленмәсен төшләрең.

*12.10.03*

## *Яшем генә олырак...*

Сабыйларның йөзе якты,
Сабый чакның юлы ак!
Мин дә шулар төсле сабый —
Яшем генә олырак...

Алар белән рәхәт миңа,
Алар барда җылырак.
Мин дә шулар төсле малай —
Яшем генә олырак...

Алар белән гомеребез
Бәхетлерәк, тулырак.
Мин дә шулар төсле бала —
Яшем генә олырак...

*2003*

## Син бит гашыйк булгансың

*Нажар Нәҗмигә*

Килде яңа шигырьләрең —
Ялкынланып язгансың.
Укыйм, укыйм, Нажар агай,
Син бөтенләй азгансың!

Шигырьләреңдә — мәхәббәт,
Хисләрнең ярсулары:
Әйтерсең лә актарылып
Агалар кар сулары!

Син бит соңлап,
Син бит чынлап
Гашыйк булгансың, картлач!
Яратып була микәнни
Карт буыннарың каткач?

Ялгыш әйттем...
Шагыйрь бит ул
Мәхәббәтнең яшьтәше.
Шагыйрьнең булмый картлыгы,
Шагыйрьнең булмый яше!

Шигырьләреңнән, үзеңнән
Куйдым әле көнләшеп...
Хәер, сөю өлкәсендә
Булмас сиңа тиңләшеп!

Сөю чыга шул шигырьгә —
Хет яшер, хет яшермә...
Без дә шулай яратырбыз
Әле синең яшеңдә!

*4.10.95*

***Нәҗар Нәҗми минем бәйрәмемдә...***

Мин аны бик көткән идем,
Көткән иде Илеш...
Килеп төште бәйрәмемә
Ул авырган килеш.

Ә килгәчтен, күз тимәсен,
Үзгәрде дә китте.
Минем төсле яшьрәкләрнең
Борынына чиртте.

Хисләре сыймый эченә,
Ургып чыга, ташып:
Җибәрде ул күлмәгенең
Изүләрен ачып.

Сөн суында басып тора...
Чәчләре ак, көмеш.
Бер ягында — Актаныш та
Бер ягында — Илеш.

Кайсы якка карарга да
Белми тора басып.
Кайсы якка караса да,
Кочаклары — ачык!..

Әллә инде иләсләнеп,
Әллә инде арып,
Бездән дә яшьрәк каенга
Сөялде ул барып.

Кереп китте каенлыкка,
Туйды бугай сүздән.
...Шигырь язып йөргән икән
Качып кына бездән.

Сабантуйда Нажар Нәҗми
Туйганчы туй итте:
Бабай булып килде дә ул,
Малай булып китте.

*9.03.99*

## *Килсен әле ул...*

*Нәҗар ага Нәҗмигә*

Барысы да соңлап килде, дисең...
Соң булса да килсен әле ул,
Хак Тәгалә сиңа тиешлене
Соң булса да бирсен әле ул.

Әнкәңнең син бер төпчеге булдың,
Тик булмадың язмыш иркәсе...
Җырның аның булмый соңлаганы,
Җырның аның юктыр иртәсе.

Иң мөһиме, шигырьләрең синең
Вакытында килде, кирәктә.
Моңга мохтаҗ чагыбызда алар
Урын алды безнең йөрәктә.

Көтүләре җиңел булмагандыр...
Түгел лә без таш бер бәгырьле.
Ә шулай да бәхетләрнең аның
Соңлаганы бигрәк кадерле!

Барысы да соңлап килде, дисең...
Үкенәсеңмени? Син нәрсә?!
Нишләр идең, гомер буе көтеп,
Бөтенләй дә әгәр килмәсә...

*9.06.99*

## *Кандаулы тау*

Кандаулыга менә мин дә мендем,
Биеклекнең түмен мин дә белдем.

Күрдем мин дә алыс киңлекләрне,
Дәрьяларны һәм иркенлекләрне.

Мондый таулар һәр күңелне яулар!
Тик һәркемгә тими мондый таулар...

Бу бит Нажар тавы, шагыйрь тавы —
Шагыйрьнең бу биек, сабыр тавы.

Шагыйрьнең мин тойдым бөеклеген...
Шагыйрь үзе никтер боек бүген.

Кемлеген ул үзе аңлый микән?
Исенә дә әллә алмый микән?

Тауга исә менә теләгәннәр,
Биеклеккә йөзен төбәгәннәр.

Менгәннәрне кире борып булмый...
Менеп була, Нажар булып булмый.

Хәер, белеп булмый...

*9.06.99*

## *Безнең җакның теле*

Безнең җакта җомшак сүләшәләр,
Көлеп тора безнең җак теле —
Безнең җакның җанлы, тере теле,
Башка җаклар өчен җат теле.

Безнең җакның теле матур ул әй,
Үзе җитди, үзе җор кебек.
Сүләшепләр генә туеп булмай,
Безнең җакның теле җыр кебек.

Җырларыбызны да шушы телдә
Сиптерәсе безгә, сибәсе.
Башкорт аны башкорт шивәсе, ди,
Татар өчен татар шивәсе.

Моның бер дә аптырарлыгы юк,
Матур телгә хуҗа табыла.
Чөнки ул бит чишмә булып җырлай,
Сөнкәебез булып агыла.

Безнең телдән кемдер көлә икән,
Колагыма да мин элмәем.
Аның кебек татлы, якты телне,
Якын телне башка белмәем.

Гомер буе шулай сүләштем мин,
Рәхәтләнеп шулай сүләем.
Шушы телем белән туганмын мин,
Шушы телем белән үләем!

*4.11.03*

## *Төрле кешеләр була*

Төрле кешеләр була:
Бүре кешеләр була,

Көлке кешеләр була,
Төлке кешеләр була,

Елдам кешеләр була,
Елан кешеләр була,

Бөркет кешеләр була,
Бер эт кешеләр була,

Былбыл кешеләр була,
Маймыл кешеләр була,

Азгын кешеләр була,
Дуңгыз кешеләр була,

Нахал кешеләр була,
Шакал кешеләр була,

Гаҗәп кешеләр була,
Бөҗәк кешеләр була,

И шәп кешеләр була,
Ишәк кешеләр була...

Синең ишеләр була,
Минем ишеләр була...

Төрле кешеләр була!

*6.11.03*

## *Син үзең киттең дә бардың...*

*Яшьлек дустым Фәннур Сафинны юксынганда язылган шигырь*

Өзә лә үзәкләремне
«Юксыну» дигән җырың.
Ул синең ачы язмышың,
Ул синең гомер юлың.

Ул синең гомер дәвамың...
Син гел безнең арада.
Син калдырып киткән моңнар
Җаннан җанга тарала.

Шагыйрьләр арасында син
Моңлы бер бала идең.
Син бит бер шигырь белән дә
Елата ала идең.

Син нечкә күңелле идең,
Шигырь һәм моң баласы...
Син үзең киттең дә бардың,
Ә безгә — моңланасы.

*1999*

## *Томан*

Иртә таңнан бар дөньямны
Томан алды томалап.
Әйтәм аны кичәдән үк
Тора иде томанлап...

Томан гына — күз алларым,
Томан гына — башларым.
Томалана башладым мин,
Тын алалмый башладым.

Томаннарны ерып барам...
Адашмаска тырышып,
Томанны да, дөньяны да,
Үземне дә орышып.

Күтәрелми дә, төшми дә,
Таралмый да бу томан.
Томан кыса, тынны кыса —
Йөрәгемә тотынам.

Куе томан...
Чыгу юлын,
Белмим, кемнән сорармын.
Томаннарны ерып барам —
Кая барып чыгармын...

*7.11.03*

## *Булалмадым...*

Мин Тукай була алмадым —
Бик яшьли үләлмәдем,
Ватанымны вә халкымны
Даннарга күмәлмәдем...

Мин Тукай була алмадым,
Туфан да булалмадым.
Туфан сөргенгә сөрелгән —
Мин анда булалмадым...

Мин Тукай була алмадым,
Такташ та булалмадым,
Хәтта лауреат билгесен
Таккач та булалмадым...

Мин Тукай була алмадым,
Җәлил дә булалмадым.
Батырлык мәсьәләсендә
Әллә ни кыралмадым.

Белмим, нишләр идем икән
Мин Алар урынында...
Роберт Миңнуллин булу да
Бик авыр әле монда.

*28.01.03*

## Сарман

Сарман, синдә Сабантуйлар!
Кемдер аек, кемдер салган...
Игеннәр мул булсын диеп,
Бәйрәм итәсең син, Сарман!

Эшлисең дә, туйлыйсың да —
Ташый синдә дәрт һәм дәрман...
Дөньяда иң булган төбәк,
Уңган төбәк синдер, Сарман!

Келәтләргә ашлык салган,
Күңелләргә шатлык салган
Төбәк бит син — терәк бит син
Бик күпләргә, изге Сарман!

Килгән саен җаннарыма
Якынаясың син һаман,
Якты Сарман, чөнки син бит
Туган якка якын Сарман!

Җыр яңгырый Сарманнарда,
Күңелләрне җыр-моң сарган...
Татарның иң моңлы җире,
Җырлы җире синдер, Сарман!

Зурлыйм сине, данлыйм сине —
Сиңа булсын, әйдә, бар дан!
Сине данлап мин һич армам,
Шулай яшик, әйдә, Сарман!

*7.06.02*

### *Патша хатыны син...*

Акчам булса, сатып алыр идем
Синең өчен алтын-көмешләр,
Алып бирер идем асылташлар...
Миннән башка аны кем эшләр?

Бик килешә сиңа читек-кәвеш,
Иң модалы плащ-пальтолар,
Затлы беләзекләр һәм йөзекләр,
Асыл туннар, ягъни мантолар.

Иңнәреңә мамык шәл ябынсаң,
Киеп алсаң затлы эшләпә,
Ким дигәндә, патша хатыны син! —
Менә кием нәрсә эшләтә...

Бар ир-атның һушын аласың син
Кичәләрдә кичке күлмәктән.
Тик белмиләр алар: син сылурак,
Син матуррак эчке күлмәктән.

*12.10.03*

## ...торам

Мин барсын да күреп торам,
Барсын да белеп торам.

Мыегым астыннан гына
Елмаеп-көлеп торам.

Кайчагында башларымны
Юләргә салып торам.

Башкалар кылган гамәлдән
Гыйбрәтләр алып торам.

Карап торам, тыңлап торам,
Мыекка чорнап торам.

Үзем дә түзем инде әй —
Дәшмичә чыдап торам.

Барсын да аңлап торам мин,
Барсын да сынап торам...

Дәшмичә күпме түзәрмен,
Дип авыр сулап торам.

*30.06.04*

### *Шулай булырга кирәк!*

Инде беләм: бу тормышта
Усал булырга кирәк.
Хәтта иң усалларга да
Мисал булырга кирәк.

Тыйнакларга көн юк бездә, —
Әрсез булырга кирәк.
Чукынып китсен дөньясы! —
Гамьсез булырга кирәк.

Мөлаемлык кирәк түгел, —
Кырыс булырга кирәк.
Нечкә күңел белән авыр, —
Корыч булырга кирәк.

Моңлыларга яшәү кыен, —
Моңсыз булырга кирәк.
Тизрәк баеп калыр өчен
Комсыз булырга кирәк.

Бакыр булсаң да, мөнбәрдә
Алтын булырга кирәк.
Безнең халык ышана ул, —
Болтун булырга кирәк.

Кеше төсле яшим дисәң,
Карак булырга кирәк!
Кирәк, ләкин азрак кына
Саграк булырга кирәк!

Гомумән, шәп кешеләрдән
Ерак булырга кирәк.
Иң әйбәте, бу дөньяда
Дурак булырга кирәк!

Ә мин дурак булалмадым...
Бик аңлыйм — бик тә кирәк!
Ләкин дурак булыр өчен
Баш җитми — акыл кимрәк.

*2002*

## *Кыш кына...*

Сер бирмәгән төсле булсам да мин,
Әй өзелә үзәк-үзәгем.
Әллә дөнья шулай өзә инде,
Әллә инде үзем өзәмен...

Бүген торсам, ап-ак булган дөнья —
Палата да ап-ак, урам да.
Аклык күчә җанга — тәрәзәдән
Ак урамга карап торам да.

Шушы аклык, шушы кышкы сафлык
Сагындыра иде еш кына...
Өметсезлекләрдән мине фәкать
Йолып алыр шушы кыш кына.

*29.10.03*

## *Син халкыңның үз шагыйре*

*Башкортстанның халык шагыйре*
*Марат Кәримовка*

Син халкыңның үз шагыйре,
Үз халкыңның даны...
Болай гына — җиңел генә
Яулап булмый аны!

Син халкыңның үз шагыйре,
Үз халкыңның зары...
Әллә кая китеп булмый
Үз халкыңнан ары.

Син халкыңның үз шагыйре,
Үз халкыңның чаңы...
Синең кебек шагыйрьләрнең
Чаңнар кагар чагы!

Син халкыңның үз шагыйре,
Үз халкыңның моңы...
Синең һәрбер шигыреңнән
Тоеп була моны.

Син халкыңның үз шагыйре,
Үз халкыңның Колы...
Нәкъ шулай булырга тиеш
Үз халкының улы!

*21.10.03*

## *Мин яшьлеккә кайткан кебек булдым*

Исертте дә, иләсләндерде дә,
Тилертте дә кызу кочагың.
Сылуланып, тулыланып киттең...
Искә төште сылу кыз чагың.

Мондый чагың синең сирәк була:
Син яшәреп киттең, яшәреп.
Мондый хәлдә безгә яратышып
Яшәрлек тә әле яшәрлек!

Син бәхеттән елагансың бугай,
Яшьләреңне сөртмәгәнсең дә...
Мин яшьлеккә кайткан кебек булдым,
Ә син әле китмәгәнсең дә.

*01.11.03*

## *Ял*

Мәшәкатьләр өйдә калды,
Бар борчулар — Казанда.
Сиңа кирәк ял итәргә,
Миңа — нидер язарга.

Үзебез — диңгез буенда,
Уебыз — өебездә.
Балаларны кайгыртабыз
Диңгездә көебезгә.

Өс-башлары бөтен микән,
Тамаклары тук микән?
Тәртипләре әйбәт микән,
Борчулары юк микән?

Акчалары калды микән,
Ничек яшиләр икән?
Ник шалтыратмыйлар икән,
Нигә дәшмиләр икән?..

Көннәрне санап барабыз,
Ял беткәнне көтәбез.
Кайту турында уйлыйбыз —
Янәсе, ял итәбез!

*31.10.03*

## *Корыч та бирешәдер...*

*Зәки Зәйнуллинга*

Зәки абзый больницада...
Йөрәген тотып ята.
Дарулар йотып ята ул,
Кайсысын тотып ата.

Авыртадыр...
Авыртканга,
Йөрәген учлап ята.
Йөрәген учлап ятса да,
Каләмен очлап ята.

Ә бит мәйдан тота иде,
Бил бирмәс егет иде.
Гомергә дә бирешмәс һәм
Авырмас кебек иде.

Йөрәге дә тимер иде,
Чыныккан корыч иде.
Һәрбер сүзе өзә торган —
Тутыкмас кылыч иде.

Мин ярый инде...
Мин — шагыйрь,
Миндә гадәти йөрәк.
Шагыйрь йөрәге авыртса,
Аптырамаска кирәк.

Минем кебекләргә әле
Чирләү дә килешәдер.
Ә Зәки абзый...
Күрәсең,
Корыч та бирешәдер.

*14.10.03*

### *Шундый ил инде менә...*

Кычкырасың — ишетмиләр...
Чукраклар иле.

Күрсәтәсең — юк, күрмиләр...
Сукырлар иле.

Сорыйсың — җавап бирмиләр...
Телсезләр иле.

Сыныйсың — дога белмиләр...
Динсезләр иле.

Исерекләр һәм угрылар,
Юләрләр иле...

Башкалар күптән гарьләнеп
Үләрләр иде.

*13.05.03*

## Алмаз улыма

Син һаман да миңа бала әле,
Син дип йөрәк һаман яна әле!..

Мин тырыштым кулдан килгән кадәр,
Мин өйрәттем сине... белгән кадәр!

Тик барсын да эшләп калалмадым,
Бу тормышның җаен табалмадым...

Мин дигәнчә генә булмады шул,
Юлларым да кайчак уңмады шул...

Минем белән тормыш вакланмады,
Өметләрнең күбе акланмады...

Шатлыгыма күпләр шатланмады,
Тик намусым, шөкер, тапланмады...

Без мәңгелек түгел беребез дә.
Бер китәрбез без дә... йөрербез дә.

Бөтен дөнья сиңа кала инде.
Дөнья авыр... үзең кара инде!

*2002*

## *Сүзсез дә аңлашабыз*

Азрак сөйлим, күбрәк тыңлыйм...
Шундыйрак минем холык.
Тел бистәләре җитәрлек —
Булмады шундый булып.

Мин бик дәшмим, чөнки беләм
Күп сүз — юк сүз икәнне.
Син, әлбәттә, яратмыйсың
Минем алай иткәнне.

Сиңа кирәк әңгәмәдәш,
Син миннән сүз көтәсең.
Тик беләсең — артык сүзнең
Нәрсә белән бетәсен.

Әллә ниләр сөйләнелә,
Иярә дә сүз сүзгә...
Мәхәббәт ул кирәк чакта
Аңлашыла сүзсез дә.

Күп сөйләшсәң, кыен була
Синең үзеңә генә.
Мин болай да карап торам
Синең күзеңә генә...

*12.10.03*

## *Кышкы сукмак. Кышкы кош*

Тап-тар сукмак, карлы сукмак...
Сукмак — ап-ак, кар — шома.
Көтмәгәндә нәни бер кош
Очып төште каршыма.

Әй карый ул кызыксынып,
Карый миңа үрелеп.
Әй ул кошның нәфислеге,
Әй андагы терелек!

Шушы кошчыкны күргәчтен
Киттем мин дә терелеп.
Юкса туңып йөрим менә
Кышкы тунга төренеп.

Болай булгач, бирешмимен,
Юк әле, юк, үлмимен!
И кошкаем, дәшәр идем,
Исемеңне белмимен.

Туңасыңдыр!
Син бит минем
Йөрәгем кадәр генә.
Җылытырмын сине, кошым,
Тоттырсаң әгәр менә.

Кошчык күзгә карады да
Очып китте җил кебек...
Күңел калды иләсләнеп,
Йөрәк калды җилкенеп.

*9.11.03*

### *Яратабыз без сезне!*

Сез беләсез инде — җилгә
Очыртмыйбыз без сүзне:
Таһир кебек, Мәҗнүн кебек
Яратабыз без сезне!

Яраттык без, яратабыз,
Мәңге яратачакбыз!
Яратуны бәйрәм саен
Кабат яңартачакбыз!..

Сезгә, әлбәттә, бәйрәмгә
Бик затлы бүләк кирәк —
Үзегездән дә гүзәлрәк,
Нәфисрәк, кыйммәтлерәк!

Каян гына алыйк икән
Сезгә ул бүләкләрне?
Шул бүләкләрне эзлибез,
Сызганып беләкләрне!..

Әгәр дә без байлар булсак,
Ташып торса акчалар,
Ул акчалар чишмә булып,
Елга булып аксалар,

Әйберләр булса кибеттә,
Сыгылып торса киштә,
Бүләкләрне сездән, кызлар,
Кызганмас идек һич тә!

О-о-о, ул чакта ниләр генә
Булмас иде табында!
Бәйрәмнәр шаулап-гөрләбрәк
Торыр иде тагын да!

Тик сез үзегез — чәчәкләр,
Алтын-көмеш — үзегез!
Мул тормышлар килер әле —
Бераз гына түзегез!

Рәхмәт сезгә — бәйрәм алып
Килгәнгә ир-атларга.
Ышанычны без, билгеле,
Тырышырбыз акларга.

Бездән калмас — рәхәтләнеп,
Китереп бөтен шартын,
Бәйрәм итәрбез кызларның
Без 8 нче Мартын!

## *Шоңкар*

*Равил Фәйзуллинга*

Шоңкарның үз биеклеге,
Шоңкарның үз колачы,

Шоңкарның үз хакыйкате...
Ә ул — татлы, ул — ачы.

Шоңкарның үз кыя ташы,
Шоңкарның үз оясы.

Кыяга оя корганчы,
Җанны күпме кыясы...

Шоңкарның үз даирәсе,
Шоңкарның үз шөгыле...

Оча алмый ул түбәндә —
Шундый холык-фигыле...

Ул биектә генә шоңкар!
Биеклек — карашында...

Югалып кала ул аста —
Чәүкәләр арасында...

Шоңкар ул әнә биектә! —
Хыялыдыр күпләрнең...

Ансыз каян күрер идең
Биеклеген күкләрнең?

*02.11.03*

### *Тимәгез!*

Телебезгә
Тимәгез!
Динебезгә
Тимәгез!
Илебезгә
Тимәгез!

Исән булса
Телебез,
Исән булса
Динебез,
Исән булса
Илебез,

Без әле баш
Имәбез!

*21.10.03*

## *Мәхәббәт турында китап*

*(Шаяру)*

Син китап укып ятасың —
Мәхәббәт хакындадыр.
Син, мөгаен, мәхәббәтнең
Җиденче катындадыр.

Бу минутта мәхәббәтең
Синең чәчәк атадыр.
Әле синең кочагыңда
Берәр егет ятадыр.

Син колагыңнан гашыйктыр,
Нишләргә белмисеңдер.
Шуңа күрә мин дәшкәнне
Колакка элмисеңдер...

Укыйсың кояш батканда,
Укыйсың таң атканда...
Ә мин укый алмас идем
Син янымда ятканда.

*11.10.03*

## *Бар да бар...*

Дәрәҗә дә,
Дан да бар.
Санлашалар —
Сан да бар.

Янып торган
Җан да бар,
Кайнап торган
Кан да бар.

Хисләр дә бар,
Аң да бар.
Аз булса да,
Мал да бар.

Янда сөйгән
Яр да бар.
Бер карасаң,
Бар да бар...

Юклары да
Табыла.
Алары күп
Тагы да...

*14.10.03*

## *Сагынуларым...*

Мин сагынмый ята алмыйм,
Мин сагынмый торалмыйм.
Мәхәббәттә дә, җырда да
Сагынмый булдыралмыйм.

Тәнкыйтьчеләр тарафыннан
Шуңа күрә тукмалам.
Тукмалсам да сагынудан,
Гомергә дә туктамам.

Ярдәм итмәс тәнкыйтьченең
Кулындагы камчы да —
Тырышсам да үзгәралмыйм,
Төзәлалмыйм тамчы да.

Сагынуларым кимеми,
Көн саен арта гына.
Алар тотам да калмыйлар —
Йөриләр арттан гына!

Сагынудан, саргаюдан
Мин күпме җыр эрләдем! —
Шул сагыну җепләреннән
Тукылган шигырьләрем.

Минем бар сагынуларым,
Моңнарым — җырларымда.
Моңаешып ята алар
Шигырем юлларында...

Ниләр эшлим соң, күңелдә
Шундый җырлар тугачтын,
Сагынырлык туган ягым,
Сөйгән ярым булгачтын...

*17.11.03*

## *Язарсың...*

*Башкорт шагыйре Хәсән Назарга*

Сине күрсәм, Хәсән Туфан белән
Нәҗәр Нәҗми төшә исемә.
Синең шигъриятең, хиссиятең
Туры килә алар хисенә.

Син алардан өйрәнгәнсең, ахры,
Кайсы сүзне кая куярга,
Шигъри сүзнең тәмен генә түгел,
Халкыбызның гамен тоярга...

Бигрәк биек — алар калдырган Сүз,
Бигрәк бөек — остазларыбыз.
Алар менгән Шигырь Кыясына
Менеп җитәр бик азларыбыз.

Остазларның Шигырь Кылы нечкә,
Остазларның Шигырь Юлы нык.
Синең шигырьгә дә күчә бара
Шул югарылык, шул олылык!

Алар язып өлгермәгәнне дә
Син язарсың әле, язарсың.
Син бит гади шагыйрь генә түгел:
Үзең — Хәсән, үзең — Назарсың.

*2000*

## *Шигырь*

Шигырь язучылар арта,
Алар хәзер меңләгән.
Бер генә кеше дә юктыр
Шигырь яза белмәгән.

Бер кеше дә калмагандыр
Шагыйрь атын алмаган.
Ә мин яза алмыйм — миңа
Юньле шигырь калмаган.

*21.10.03*

## *Кай арада үстең әле?*

*Кызым Таңсылуга*

Кай арада үстең әле?
Әйт әле, син ничәдә?..
Синең үскәнеңне, кызым,
Калганмын сизмичә дә.

Ышанасым килми хәтта
Шулай тиз үскәнеңә —
Кайчан гына әле синең
Бишектән төшкәнеңә.

Үскәнсең инде, үскәнсең —
Мине дә уздыргансың.
Талчыбыктай зифа буйлы
Сылу бер кыз булгансың.

Миңа карыйсыңдыр инде
Биектән, өстән генә...
Ә мин сиңа карыймын да
Сокланам эчтән генә.

Син минем акыллы кызым,
Син минем берләч кызым.
Дөньяларым яктыра, син
Елмайгач-көлгәч, кызым.

Тыңлаучан кызым син минем,
Кайчак — үзсүзле кызым.
Таңнар төсле алсу йөзле,
Ямь-яшел күзле кызым.

Сөйләшкәндә, серләшкәндә
Мин сине аңлыйм кебек,
Кайчагында аптырыйм да —
Аңлый да алмыйм кебек.

Төн төсле серле кызым син,
Көн төсле ачык кызым.
Матур булып, матур итеп
Яшәргә ашык, кызым!

Бәхетеңә ашык, кызым,
Алларыңа кара да!..
Шулай да әйт әле, кызым,
Үстең син кай арада?

*24.10.03*

## *Сине көтеп яшим*

Гомер буе сине көтәм,
Сине көтеп яшим...
Ерак юлга чыгып китсәм,
Чыгып китсәң йә син.

Гомер буе сине көтәм:
Чит-ят якларда да,
Аерылып торган чакта,
Бергә чакларда да.

Көннәр буе, айлар буе,
Еллар буе көтәм.
Гомер буе көтә торган
Бер кешем юк бүтән.

Нәрсә ул сагыш, сагыну,
Елау, күңел тулу...
Иң мөһиме — бу дөньяда
Көтәр кешең булу!

*19.10.03*

* * *

Күктә күпме йолдызлар!..
Үзләре бергә дә төсле,
Ә үзләре — ялгызлар...

Читтән карасаң, кешенең
Сизелми ялгызлыгы...
Без дә бит — йолдызлар...
Без дә —
Кешелек йолдызлыгы...

Һәрберебез —
Бер йолдыз без,
Һәрберебез —
Бер ялгыз...

*29.11.03*

## *Кырымның көньяк ярлары...*

Кырымның көньяк ярлары...
Үзе ят та, таныш та.
Ялда ятам — янда гына
Ялта, Форос, Алушта...

Кырымның көньяк ярлары...
Килсәң, борчулар бетә.
Гомер буена шушында
Яшәүчеләр бар бит, ә?!

Кырымның көньяк ярлары...
Гөлбакчалар иңләгән.
Шагыйрьләр бу урыннарны
Гел җәннәткә тиңләгән.

Кырымның көньяк ярлары...
Калырлык шул гаҗәпкә!
Ярар иде... үлгәчтен дә
Эләксәң бу җәннәткә.

*29.10.03*

## *Төнге диңгез*

Сыендырды безне төнге диңгез,
Ай яктыртып торды йөзеңне.
Су кызы дип, диңгез кызы диеп
Хис итәсеңдер син үзеңне.

Төнге диңгездә без бер кайгысыз
Ике дельфин кебек уйнадык.
Бу мизгелдә — төнге бу диңгездә
Бер без генәдер дип уйладык.

Төнге рәхәт диңгез. Икебезнең
Бәхетебез бүген бертигез...
Икебезгә җитә бер айлы төн,
Икебезгә җитә бер диңгез.

*29.10.03*

## *Кайткан идек без дә Илешкә*

*Рәдифкә, Гәрәйгә, Ринатка*

Исегездә микән, әй егетләр,
Кайткан идек бит бер Илешкә.
Сабантуйлар каршы алган иде
Без Илешкә кергә-керешкә.

Биш хыялый идек без ул чакта
(Ризван Хәмид иде беребез).
Безгә бик тә рәхәт иде анда,
Әй улаган иде бүребез.

Исән иде әле Ринат Хәйри, —
Без кунакта булдык аларда.
Ә аннары бергәләшеп киттек
Илеш Сабантуен карарга.

Мин күрсәтеп йөргән идем сезгә
Яшеллеккә чумган Яркәйне,
Шәммәтемне — туган нигеземне
Һәм, әлбәттә инде, Әнкәйне.

Ә ул сезгә, күчтәнәчкә диеп,
Каклаган каз биреп җибәрде.
Истә әле, казны күргәч, Гаташ
Шатлыгыннан биеп җибәрде.

Аннары без кыр казлары төсле
Очып киткән идек Казанга.
(Күпме йөрдем бит мин шушы хакта
Юньлерәк бер шигырь язарга...)

Без яңадан туган нигеземдә,
Күзләремә тагын яшь тулган.
Без гел элеккечә... Миңа гына
Ни өчендер илле яшь тулган.

*1999*

## *Юл буенда чибәр туташ*

Юл буенда чибәр туташ
Кыланып тора,

Киемнәре тәннәренә
Сыланып тора,

Ярты «хәзинә»сен туташ
Чыгарып тора,

Юл буенда ул мәхәббәт
Соранып тора...

Күзләре генә нигәдер
Чыланып тора.

*25.11.03*

## Телевизор караганда

Күк күкрәүләр,
Җир тетрәүләр,
Су ташулар,
Су басулар,
Батулар һәм
Атулар...
Тик фактлар:
Терактлар,
Норд-Остлар,
Блокпостлар,
Триллерлар,
Киллерлар,
Бандитлар һәм
Вампирлар...
Афәтләр,
Ураганнар,
Талаганнар,
Урлаганнар...

Түзәбез әле
Әле дә...
Әлегә!

*10.10.03*

## *Яшик әле!*

Яшик әле!
Бу дөньяда
Ниләр генә булмасын! —
Йөрәк кенә сынатмасын,
Йөрәк кенә тынмасын!

Яшик әле!
Тартып бара
Атлар гомер арбасын! —
Атлар гына абынмасын,
Атлар гына армасын!

Яшик әле!
Күңелләрдә
Сөю генә үлмәсен! —
Ярлар гына янда булсын,
Хисләр генә сүнмәсен!

Яшик әле!
Халкым гына
Бүтән афәт күрмәсен! —
Исән генә була күрсен,
Хәсрәт кенә белмәсен!

*17.11.03*

## *Син нигә шундый чибәр?*

Күзләрең серле елмая,
Күңлеңдә синең ниләр?..
Син нигә шундый серле соң,
Син нигә шундый чибәр?

Синең бер елмаюыңнан
Ямьсезлек артка чигәр...
Син нигә шундый сөйкемле,
Син нигә шундый чибәр?

Карама усал иттереп —
Югыйсә гайрәт чигәр...
Син нигә шундый тәкәббер,
Син нигә шундый чибәр?

Синең белән кем чиләнер,
Кем генә рәхәт чигәр...
Син нигә шундый хәйләкәр,
Син нигә шундый чибәр?

Килмәсен сиңа картлыклар,
Тимәсен сиңа чирләр...
Нигә син шундый акыллы,
Нигә син шундый чибәр?

*31.01.03*

## *Онык*

*Оныгым Регинага*

Онык кына хәзер телебездә,
Онык белән уза көнебез дә,

Аның белән уза төнебез дә —
Шау-гөр киләбез бөтенебез дә!

Оныгыбыз барсын оныттыра:
Төрле-төрле чагы булып тора,

Шуклыкларын һаман кылып тора,
Тынса да ул бик аз тынып тора.

Үсеп килә сылу булып кына,
Алсу алма төсле тулып кына!

Алмаз төсле затлы булып кына!..
Бөтен шатлыгыбыз — онык кына!

Бер карасаң, әле кечкенә бит,
Бер карасаң, үзе олы гына!

Әле генә туган кебек иде,
Өч яшь тула инде оныгыма!

Җитсә әле дүртләр, җитсә бишләр,
Минем кызым әле әллә нишләр!

Сүзе үткен аның, үзе үткен —
Әллә типтәр кызы, әллә мишәр?

Бар дөньябыз хәзер — онык кына,
Йөрим хәзер бабай булып кына —

Аның бәхетенә, саулыгына
Йөрим хәзер дога кылып кына!

Калган эшләр пока торып тора!

*15.11.03*

## *Очты да китте бер Күңел*

*Софья Гобәйдуллинага*

Очты да китте бер Күңел...
Ул инде безнеке түгел.

Ул шул инде читләрнеке...

Ирек сөйгән ул Күңелне
Читлекләргә бикләрлекме?

Очкан күге — чит илләрдә,
Йөзгән күле — чит җирләрдә...

Кайчакларда очып кына
Иленә дә килеп китә —

Җилпенгәндә, канат җиле
Күңелләргә тиеп китә...

*26.11.03*

## *Рәхәт яшибез!*

Ай-яй рәхәт яшибез —

Өйгә ризык ташыйбыз!
Ашыйбыз да эчәбез,
Эчәбез дә ашыйбыз...
Аннан корсак кашыйбыз!
Артып калса, ташлыйбыз...
Аннарымы? Аннары
Өр-яңадан башлыйбыз:
Ташыйбыз да ашыйбыз,
Ашыйбыз да ташлыйбыз...

Шулай рәхәт яшибез!

*26.11.03*

### *Кил әле!*

Кил әле тагын Казанга,
Башкорт дустым Янбәк!
Кил әле, утыр әле бер
Табынымны ямьләп.

Сөйләшик әле туйганчы,
Эчик әле тәмләп.
Күптән инде күрешкән юк,
Сөйләшкән юк, Янбәк.

Минем дуслар простой түгел:
Йә шагыйрь дә йә бәк!
Ә син исә икесе дә,
Дустым Рәмил Янбәк.

Яз әле син, сәләтеңне
Торма әле җәлләп.
Син бит шагыйрь,
Шагыйрьнең дә
Ниндие бит, Янбәк?!

Көтәдер безне тегендә
Җәһәннәм йә җәннәт...
Кайда эләксәк тә, бергә
Булыйк әле, Янбәк!

*16.07.99*

## *Ике йөзем*

Түшләреңдә синең ике йөзем...
Йөземнәрдә генә ике күзем.

Йөземнәрне ничек кенә өзим,
Авыз итми ничек кенә түзим?

Түшләреңдә синең ике йөзем.
Йөземнән дә татлыдыр син үзең...

*25.11.03*

## *Битаман*

*Рафис Корбанга*

Мин сине күптән ишетеп
Белә идем, Битаман.
Син матур икән, үзеңә
Матурлыгың тап-таман!

Бер күргәч тә гашыйк булдым,
Гашыйк булдым бит тәмам.
Шулай булгач, гади авыл
Түгелдер син, Битаман.

Кызларыңны күрүгә үк
Алсуланды бит алмам.
Болай булса, башларымны
Бетерәсең, Битаман!

Кызларыңа бер булса да
Күз салмыйча киталмам.
Аннан гына берни булмас —
Гаеп итмә, Битаман!

Чынлап гашыйк булсам әгәр,
Китә алмам бит аннан...
Гомер булса, сиңа тагын
Бер килермен, Битаман!

*12.03.03*

## *Саллар акмаслар инде...*

Саллар акмаслар шул инде,
Саллар акмаслар инде...
Агыйделнең ярларын да
Саллар какмаслар инде.

Саллар акмаслар шул инде,
Саллар акмаслар инде...
Егетләр сал өсләрендә
Учак якмаслар инде.

Саллар акмаслар шул инде,
Саллар акмаслар инде...
Салда барган егетләргә
Кызлар бакмаслар инде.

Саллар акмаслар шул инде,
Саллар акмаслар инде...
Элеккечә алсу булып
Таңнар атмаслар инде.

Саллар акмаслар шул инде,
Саллар акмаслар инде...
Алар агып кына китә —
Кабат кайтмаслар инде.

Саллар акмаслар инде...

*26.11.03*

### *Котылу юк сездән!*

Сездәй хатын-кызлар бездә генә,
Сездәй хатын-кызлар беркайда юк.

Сезне яратабыз, әмма ләкин
Сезне яратудан бер файда юк.

Сезнең үткен, ут, мут карашыгыз
Телебезне безнең бәйләндерә.

Йөрәкләребезне җилкендерә,
Башыбызны безнең әйләндерә.

Әйләндерсә генә ярар иде,
Югалттыра кайчак башыбызны.

Оныттыра бөтен дөньябызны,
Оныттыра ашар ашыбызны.

Рәхмәт инде — безне аздырасыз,
Аздырасыз безне, туздырасыз.

Күзебезне безнең кыздырасыз,
Акылларыбыздан яздырасыз.

Нилектәндер безнең җаннарыбыз
Сезнең чибәрлектән эреп китә.

Төп-төз генә барган җиребездән
Кыек юлга алып кереп китә.

Һәм чирләргә безне сабыштыра —
Безне гүя пәри алыштыра.

Сезнең хакка күпме утлар кичтек,
Башка яратмам, дип антлар эчтек.

Сүзебездә ләкин торалмадык,
Сездән башка берни кыралмадык.

Сез, ахрысы, пәри затыннандыр,
Сез иблискә, ахры, сатылгандыр...

Ничек итсәгез дә итегез лә,
Чукынышлар гына китегез лә...

Без картайган саен сез матуррак,
Без бөкрәйгән саен сез турырак.

Сез һаман да матур, чибәр, гүзәл,
Бу йөрәкләр, белмим, күпме түзәр?!

Котылу юк сездән үлгәндә дә,
Сезсез булмас, ахры, гүрләрдә дә.

Рәхмәт инде — газап чиктердегез,
Кирәк чакта гашыйк иттердегез,

Бик кыланып тормадыгыз алай —
Кочтырдыгыз һәм дә үптердегез.

Кирәк чакта юлдан яздырдыгыз,
Чама белеп кенә аздырдыгыз.

Рәхмәт сезгә, инде азып туйгач,
Шушы шигыремне яздырдыгыз.

*7.03.03*

## *Кая югалдыгыз, татарларым?!*

*2002 елгы җанисәптән соң юкка чыккан 200 меңнән артык Башкортстан татарына мәрсия*

Кая булдыгыз сез, татарларым?
Әллә сезне утка тыктылармы?
Әллә инде суга салдылармы,
Йә булмаса тупка тоттылармы?

Кая югалдыгыз, татарларым? —
Кичә генә әле бар идегез,
Бар идегез, татар идегез бит,
Татарларыбызга пар идегез!

Кая булдыгыз сез, татарларым? —
Хөкемнәргә сезне тарттылармы?
Астылармы сезне, аттылармы?
Төрмәләргә әллә яптылармы?

Килмешәкләр диеп сөрделәрме,
Башка юлын әллә таптылармы?
Әллә инде башка бер халыкка
Коллар итеп сезне саттылармы?

Әллә инде үз-үзегезне сез
Җиңел генә шулай саттыгызмы?
Әби-бабайларның әманәтен
Чүплекләргә тотып аттыгызмы?

Әллә инде милләтегезне сез
Бер яртыга сатып эчтегезме?

Нәрсә булды сезгә, милләттәшләр? —
Шушы көнгә килеп төштегезме?

Ә башкалар әнә үрчи тора, —
Татарларны әллә печтеләрме?
Ник дәшмисез, нигә эндәшмисез —
Телегезне әллә кистеләрме?..

Мин беркемне гаепләмим монда,
Мин бит бары авыр сулыйм гына.
«Кая югалдыгыз, татарлар?» — дип,
Мин бит сездән бары сорыйм гына...

Кая булдыгыз сез, татарларым?
Сез кайларга китеп югалдыгыз?
Канлы гасырлардан исән чыгып,
Ничек кенә болай булалдыгыз?

Ишетелә кебек ераклардан
Зарларыгыз сезнең, аһларыгыз...
Яу кырында ничек сирәгәйсә,
Сирәгәя шулай сафларыгыз.

«Каравыл!» дип бөтен дөньясына
Нигә әле оран салмадыгыз?
Ниләр эшләр менә киләчәктә
Бу афәттән исән калганыгыз?..

Ниләр булды сезгә, татарларым? —
Ни дисәң дә, сезгә сүз юк инде.
Җиңел булсын авыр туфрагыгыз! —
Татар өчен хәзер сез юк инде...

Яңа гасырлардан эзләр әле
Улларыгыз сезне, оныгыгыз!..
Йә, хушыгыз! Йә, бер дога кылыйк!
Җәннәтләрдә булсын урыныгыз!

*14.11.03*

## *Мин төн буе сине уйлап яттым*

Мин төн буе сине уйлап яттым,
Күзләремә йокы кермәде.
Сине уйлаганны Ходай күрде,
Аннан башка беркем күрмәде.

Мин төн буе сине уйлап яттым,
Йөрәгемне кысып учыма.
Сине уйлап яттым — уйларымның
Чыга алмадым мин очына.

Мин төн буе сине уйлап яттым,
Тик син генә булдың җанымда.
Төннәр хәзер шундый озын икән —
Син булмагангадыр янымда.

Мин төн буе сине уйлап яттым,
Ходай сине үзе сакласын!
Сине уйлап мин туймадым әле —
Таң атмыйча торсын, атмасын!

Мин төн буе сине уйлап яттым,
Ә шулай да таңны аттырдым.
Сине уйлап, сине генә уйлап,
Таңнар белән мин дә яктырдым!

*19.10.03*

## *Җәйнең бер көне*

Җәйнең бүген кыл уртасы,
Җәе тора чыңлап.
Җәйнең шушы эссе көне
Җәннәт төсле! Чынлап!

Җәй уртасы җем-җем итә,
Җәй уртасы гөжли.
Монда бар да хәрәкәттә,
Бар да нидер эзли.

Кырмыскалар, бал кортлары
Тотынганнар эшкә.
Чикерткәләр сикерешә,
Килеп төшә өскә.

Менә нәфис бер күбәләк
Килеп кунды чәчкә.
Гүя мин дә бер үсемлек,
Гап-гади бер чәчкә.

Йә булмаса бер камка мин,
Ямь-яшел бер үлән.
Шуларның берсе икәнне
Мин үзем дә беләм.

Һәр үләннең үз бөҗәге,
Һәрберсе бер бизәк.
Аларга ят тоеладыр
Минем кебек бөҗәк...

Истән чыкты фани дөнья,
Онытылды кышлар.
Сайрашып ага чишмәләр,
Челтериләр кошлар.

Ул кошларның көйләрен мин
Беләм инде яттан...
Бер хәсрәте юк кешедәй
Рәхәтләнеп ятам!

*1997*

## *Кыска булды гомеркәең*

*Сеңелебез Алия Миңнуллинаның*
*якты рухына*

И Алия сеңелкәем,
И әрни лә күңелкәем.
Бигрәкләр дә кыска булды,
Кыска булды гомеркәең.

Бигрәк иртә китеп бардың,
Тормыш тәмен тоймас борын...
Китеп бардың изге айда —
Оҗмахтадыр синең урын.

Иң яраткан кешеләрен
Ходай ала үз янына.
Ышанам мин: Ходай сине
Сыендырыр үз җанына.

Сине искә алган саен,
Йөрәккәем и сызылыр...
Оҗмахта да син Ходайның
Иң яраткан бер кызыдыр...

Шәмнәр төсле эреде дә,
Сүндең инде, сеңелкәем.
Бигрәкләр дә кыска булды,
Кыска булды гомеркәең.

*5.11.03*

## *Бу җырым мәхәббәт хакында*

Очабыз без ерак-еракка
Сөюнең канатлы атында.
Өзелеп яраткан чагында
Без күкнең җиденче катында.

Мәхәббәт булмый ул еракта,
Булмый ул диңгезләр артында.
Эзләмик без аныерактан —
Мәхәббәт ул янда, якында!

Сөябез үзебезнекен дә,
Сөябез кайчакта ятын да —
Янсак та янабыз бары тик
Мәхәббәт исемле ялкында.

Янабыз, көябез, сөябез —
Күңелдә мәхәббәт талпына!
Барсы да мәхәббәт хакына!
Бу җырым мәхәббәт хакында!

*19.11.03*

### *Бик кирәк булсам...*

Арагызда гел булалмам,
Китәрмен бер көн...
Китүемне бәлки әле
Сизмәс тә беркем.

Мин булырмын сез белмәгән
Чит-ят якларда.
Бәлки, кайтып та йөрермен
Мин кайчакларда.

Югалтмагыз, арагызда
Бик сирәк булсам...
Шигырьләремнән табарсыз,
Бик кирәк булсам.

*1999*

### *Кайт, Салават!*

Кайт, Салават, башкортыңа,
Кайт, Салават, Иленә!
Сал инеңә ук-җәяңне,
Так кылычың биленә!

Кылычың синең үткен бит,
Җырың синең — ялкынлы.
Кайт, Салават, кайт син безгә,
Күтәр, әйдә, халкыңны!

Син кирәк чаклар еш була,
Син һәрчак кирәк безгә.
Чынын әйтсәм, синең кебек
Егетләр сирәк бездә.

Хәлләребез һаман шул ук,
Үзгәрмәгән тамчы да.
Яраларың безгә күчкән —
Һәрберсеннән кан чыга.

Әллә инде көчсезлекме,
Әллә инде гамьсезлек, —
Әле һаман яуланмаган
Син көрәшкән бәйсезлек.

Әле һаман мактанырлык
Түгел әле хәлебез.
Ни булса да, бирешергә
Тиеш түгел әле без!

Көтә сине башкорт, татар —
Күңелләре тулы моң...
Кайт, Салават! Гаскәреңдә
Бер яугирең булырмын!

*19.06.04*

## *Җырны булмый үтереп*

*Татарның бөек җырчысы*
*Рәшит Ваһапов ядкәре*

Татар җанына җыр кирәк!..
Җырсыз туңмыйсыз микән?
Ә мин Ваһаповны тыңлыйм,
Сез дә тыңлыйсыз микән?

Татар Халык Моңы бит ул,
Татар Халык Бәгыре!
Ә халык бәгырьләренең
Бармы бездә кадере?!

Җырны булмый оныттырып,
Җырны булмый бетереп.
Җырчы үлә, җыры кала —
Җырны булмый үтереп!

Җырлары аның мәңгелек,
Җырлары аның җылы.
Туңган җаннарыбызны да
Җылыта аның җыры.

Җырланган җыр яңара ул,
Җырланган җыр тузмый ул.
Яра булып сызлый ул җыр,
Җаннан мәңге узмый ул...

Ә мин Ваһаповны тыңлыйм,
Сез дә тыңлыйсыз микән?

Тыңлаганда минем кебек,
Сез дә елыйсыз микән?

Татар җыры — татлы җыр шул,
Татар җыры — ачы җыр.
Ачы җырлар тыңлый-тыңлый
Җаннар күпме ачыныр?!

Йомылган татар күңеле
Шул җырлардан ачылыр!
Яна, яна татар җаны...
Бәлки әле басылыр?

Җырлансын җыр,
Тыңлансын җыр,
Тормасын җыр суынып.
Татар бетәр, бәгыреннән
Җырын алсаң суырып...

Ә мин Ваһаповны тыңлыйм,
Сез дә тыңлыйсыз микән?
Минем кебек тыңласагыз,
Ниләр уйлыйсыз икән?

*21.04.04*

## *Рифмалар*

* * *

Безнең урамда ачылды
Супермаркет!
Синең барыбер акчаң юк —
Сыпырт, бар кит!

*29.08.96*

* * *

Королева
Монсоро!
Ә безнеке —
Моңсара!

* * *

Америкада — Клинтон,
Франциядә — Жак Ширак,
Әмма Минтимер Шәймиев
Барсыннан да яхшырак!

*1997*

* * *

«Салават» җыр театры
Һәм дә «Союз-дистрибьюшн»
Җиң сызганып башладылар
Яшь талантлар үстерү эшен!

## *Алма*

Яшел алмага текәлдем —
Кызарып пеште.

Тагын бер караган идем —
Өзелеп төште.

Авызымны ачкан идем —
Башымны тиште!

*12.10.96*

### *Түбәндә*

Түбәндә яшәү дә әйбәт,
Билгеле бер күләмдә.
Егылсаң да берни булмый —
Шунсы рәхәт түбәндә.

*1996*

### *Б.Н.Ельцинга ачу килгәч...*

Америкага
Буш баш.
Ә безнеке —
Буш баш.

*1997*

* * *

Чиксезлектә —
Мәңгелек...

Мәңгелектә —
Тәңрелек...

*01.01.03*

### *Көнләшүчеләргә*

Бик сыек бит шигырь язган
Язу карагыз...
Башта сез минем шикелле
Язып карагыз!

*1997*

* * *

Күкрәк сугучылар артты.
Күпкә китте, күбрәккә...
Тик суктың ни, сукмадың ни
Андый тап-тар күкрәккә.

*1997*

### *Хәсән Сарьян шаяруы*

Мин үзем гармун уйнамыйм,
Уйный белмим берни.
Менә минем абыем бар...
Ул да уйный белми.

*1995*

* * *

Мин күп яздым инде — күрдем инде
Язганнарымның мин казасын...
Язылмаганнары өчен дә бер
Алачакмын әле җәзасын...

*Август, 2001*

* * *

Зарлансаң, зарлар җитәрлек
Кемдә дә:
Анда да зар, синдә дә зар,
Миндә дә...

Тик мин бер дә зарланмаска
Тырыштым —
Кайчан җиңел булганы бар
Тормышның?

*18.11.98*

* * *

Соңгы вакытларда миндә
Дәрт һәм дәрман тарткалаша:
Әллә инде кайнар тай мин,
Әллә инде карт алаша?!

*1997*

* * *

Шагыйрь булсаң, дөрләп кенә,
Янып-көеп кенә була.
Шагыйрь гади була алмый,
Шагыйрь бөек кенә була!

*22.04.2000*

## *Реклама*

Тәмәке —
Зарарлы...
Ташлагыз!
Тәмәке —
Зараза...
Ташлагыз!
Булмаса,
Яңадан
Башлагыз!
Яңадан
Ташлагыз...
Яңадан
Башлагыз...
Яңадан
Ташлагыз...

Күп кеше
Шулай итә...
Теге дөньяга
Китә...

*27.01.03*

### *Имеш тә...*

Юк байлыгым, юк хәзинәм,
Юк алтын да, көмеш тә...
Мин дә гомер сөрәм инде —
Олы түрә, имеш тә!

*28.01.03*

### *Пирамида*

Бөтен дөнья башын ватсын әле,
Мисыр белән Иран уйлансын:
Ничә гасыр төзеделәр икән
Казанның бу пирамидасын?!

*21.12.02*

* * *

Бөркетләр
Тауда туа,
Батырлар
Яуда туа!

*2002*

* * *

Күршем бик бай, әмма ләкин
Рухы — мескен, җаны — фәкыйрь...
Минем исә киресенчә:
Күңелем — бай, кесәм — такыр...

Шулай...
Икебез дә фәкыйрь,
Икебез дә бай.

*2002*

## *Мәзәк*

Маймыл агачка үрмәли,
Иң очына үреләө.
Үзе өскә менгән саен,
Күте ныграк күренә.

* * *

«Вөҗдан» да «вөҗдан» дибез...
Дибез генә шул.

Вөҗдан хәзер сүз генә,
Девиз гына шул.

*31.10.03*

* * *

Шагыйрьләр басты...
Югыйсә
Бер Тукай җитәр иде —
Һәркемне үз урынына
Утыртып китәр иде.

*21.09.03*

## *Девальвация*

Бу заманда шигырь язу
Иң җиңел бер шөгыль.
Тик «шагыйрьләр» арткан саен,
Кими бара шигырь.

*19.10.03*

## *Нигәдер...*

Дөнья тулган кызлар белән...
Әй ул матурлыклары!
Тик нигәдер сирәк очрый
Мин яратырлыклары...

*12.05.03*

## *Ярат кына!*

Яратып булмый «яратам!»
Диюгә карап кына.
Миңа «яратам!» дип әйтмә,
Син мине ярат кына!

*12.05.03*

## Арынырбыз...

Мәчетләр бар хәзер, хәзрәтләр бар.
Намазлар да, шөкер, укыла...
Тик гөнаһтан арынырбыз, ахры,
Кереп кенә тәмуг утына.

*13.05.03*

## *Тую...*

Үзебез туйдык шикелле,
Туймый күзебез генә.
Шөкер итик! —
Илебез бай!..
Ярлы үзебез генә.

*13.05.03*

### *Илаһилык*

Илаһилык —
Даһилык!..

Илаһилык —
Бакыйлык!..

Илаһилык —
................

*27.11.03*

### *Шундыйрак чагым...*

Дөньяның яме китте,
Халыкның мәне китте,
Милләтнең хәле китте,

Шигырьнең тәме китте,
Җанымның гаме китте...

Язмышмы шулай итте,
Тормышмы шулай нитте?..

Шундыйрак чагым җитте...

* * *

Вакыт үлми, туктамый...
Вакыт ул мәңгелек!
Вакытның үз эчендә
Киләчәк һәм Элек...

## *Безгә дигәч кенә...*

Барыбыз да талантлылар,
Барыбыз да бик осталар...
Безгә чират җиткәч кенә
Буш түгел шул пьедесталлар!

*27.01.03*

### *Җитә...*

Кешене кол итәр өчен
Зынҗыр җитә...
Ә коллыктан коткарырга
Чын Җыр җитә.

*2003*

### *Авырып ятканда*

Яткан урыным —
Комфортабельный,
Хәлләрем генә —
Инфарктабельный...

## Эчтәлек

Мин яратам сезне, чордашларым! . . . . . 4
Күпме шигырь яздым... . . . . . . . . . . . . . 6
Минме? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
Беләм мин үзем генә... . . . . . . . . . . . . 8
Күзгә керүләре авыр... . . . . . . . . . . . . 9
Сиңа бик кыен булгандыр... . . . . . . . . 10
Уйландыра икән... . . . . . . . . . . . . . . . 12
Сак-Соклар без... . . . . . . . . . . . . . . . 13
Уфадагы дусларым . . . . . . . . . . . . . . 14
Хатын-кыз ямьсез булалмый . . . . . . . 16
Остазларым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 18
Юка иңнәреңнән кочам да... . . . . . . . . 19
Манзара . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 20
Еникине дә озаттык... . . . . . . . . . . . 21
И әнкәем — сыңар канат... . . . . . . . . 22
Шигырьне мин үзем язмыйм . . . . . . . . 23
Яфрак туе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 24
Без яшьлектән килгән ике хат . . . . . 25
Бер Бөркет бар Уралда . . . . . . . . . . . 26
Чиләбе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 28
Гарәп илендә . . . . . . . . . . . . . . . . . 29
Син һаман сер . . . . . . . . . . . . . . . . . 30
Гомер Сабантуе . . . . . . . . . . . . . . . . 32
Күзләр белән бергә . . . . . . . . . . . . . 34
Әнкәйне сайлап алмыйлар . . . . . . . . . 35
Үзебез! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 36
Мин борчылып яткан булам . . . . . . . . 37
Сәйдәш. «Шәрык биюе» . . . . . . . . . . 38
Өйрәнеп кенә киләм... . . . . . . . . . . . 40

Китәләрдер инде... 41
Без Илештән чыгып киткән чакта 42
Кеше гомерләре бигрәк кыска... 44
Татар 45
Чүплектәге шигырьләр 46
Син бит мондый түгел идең... 47
Елатма инде Әнкәйне... 48
Әверелеш 49
Күңелләр нечкәргәндә... 50
Кычыту 51
Синең чәчләр әле кара иде 52
Яшь алмыйм синсез... 54
Тагын салкыннар башлана... 55
Герман күге — кара кайгы 56
Өлгерербез! 58
«Тормыш булсын өчен...» 59
Сәхнә 60
Син әле дә матур... 62
Биләр 63
Әнкәең бигрәк ягымлы 64
Шаяру 65
Җәй хатирәсе 66
Күз тимәсен сиңа, Мостай! 67
Яңа ел тосты 68
Җырладың син «Каһым түрә»не 70
Шагыйрьләрнең газиз аналары 72
Бүленмәсен төшләрең 73
Яшем генә олырак... 74
Син бит гашыйк булгансың 75
Нәҗар Нәҗми минем бәйрәмемдә... 76
Килсен әле ул... 78

Кандаулы тау . . . 79
Безнең жакның теле . . . 80
Төрле кешеләр була . . . 81
Син үзең киттең дә бардың... . . . 82
Томан . . . 83
Булалмадым... . . . 84
Сарман . . . 85
Патша хатыны син... . . . 86
...торам . . . 87
Шулай булырга кирәк! . . . 88
Кыш кына... . . . 90
Син халкыңның үз шагыйре . . . 91
Мин яшьлеккә кайткан кебек булдым... 92
Ял . . . 93
Корыч та бирешәдер... . . . 94
Шундый ил инде минә... . . . 96
Алмаз улыма . . . 97
Сүзсез дә аңлашабыз . . . 98
Кышкы сукмак. Кышкы кош . . . 99
Яратабыз без сезне! . . . 100
Шоңкар . . . 102
Тимәгез! . . . 103
Мәхәббәт турында китап . . . 104
Бар да бар... . . . 105
Сагынуларым... . . . 106
Язарсың... . . . 108
Шигырь . . . 109
Кай арада үстең әле? . . . 110
Сине көтеп яшим . . . 112
«Күктә күпме йолдызлар!..» . . . » 113
Кырымның көньяк ярлары... . . . 114

Төнге диңгез . . . . . . . . . . . . . . . . 115
Кайткан идек без дә Илешкә . . . . . . . . 116
Юл буенда чибәр туташ . . . . . . . . . . . 118
Телевизор караганда . . . . . . . . . . . . . 119
Яшик әле! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 120
Син нигә шундый чибәр? . . . . . . . . . . 121
Онык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 122
Очты да китте бер Күңел . . . . . . . . . 124
Рәхәт яшибез! . . . . . . . . . . . . . . . . . 125
Кил әле! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 126
Ике йөзем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 127
Битаман . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 128
Саллар акмаслар инде... . . . . . . . . . . 129
Котылу юк сездән! . . . . . . . . . . . . . 130
Кая югалдыгыз, татарларым?! . . . . . . 132
Мин төн буе сине уйлап яттым . . . . . 135
Җәйнең бер көне . . . . . . . . . . . . . . . 136
Кыска булды гомеркәең . . . . . . . . . . 138
Бу җырым мәхәббәт хакында . . . . . . . 139
Бик кирәк булсам... . . . . . . . . . . . . . 140
Кайт, Салават! . . . . . . . . . . . . . . . . 141
Җырны булмый үтереп . . . . . . . . . . . 143
Рифмалар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 145
Алма . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 147
Түбәндә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 148
Б.Н. Ельцинга ачу килгәч... . . . . . . . . 149
«Чиксезлектә...» . . . . . . . . . . . . . . . 150
Көнләшүчеләргә . . . . . . . . . . . . . . . 151
«Күкрәк сугучылар артты...» . . . . . . . 151
Хәсән Сарьян шаяруы . . . . . . . . . . . 152
«Мин күп яздым...» . . . . . . . . . . . . . 152

«Зарлансаң...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 153
«Соңгы вакытларда...» . . . . . . . . . . . . . . 154
«Шагыйрь булсаң...» . . . . . . . . . . . . . . . 154
Реклама . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 155
Имеш тә... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 156
Пирамида . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 156
«Бөркетләр...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 157
«Күршем бик бай...» . . . . . . . . . . . . . . . . 158
Мәзәк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 159
«Вөждан» дибез...» . . . . . . . . . . . . . . . . 160
«Шагыйрьләр басты...» . . . . . . . . . . . . . 161
Девальвация . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 162
Нигәдер... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 163
Ярат кына! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 164
Арыныpбыз... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 165
Тую... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 166
Илаһилык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 167
Шундыйрак чагым... . . . . . . . . . . . . . . . . 168
«Вакыт үлми...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 169
Безгә дигәч кенә... . . . . . . . . . . . . . . . . . 169
Җитә... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 170
Авырып ятканда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 170

Литературно-художественное издание

***Миннуллин Роберт Мугаллимович***

**КОГДА ДУША ТОСКУЕТ...**

*Стихи*

(на татарском языке)

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Н.П.Клипова*
Корректоры *Г.Г.Гарифуллина*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия 2001 елның
6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 5.07.2004. Форматы 70×90 $^1/_{32}$.
Офсет кәгазе. «Times» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 6,44 + фор.0,15. Шартлы буяу-оттиск 7,32.
Нәшер-хисап табагы 4,31 + фор.0,26. Тиражы 2000 д. Заказ Э-449.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул.Баумана, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы дәүләт унитар предприятиесе. 420066. Казан, Декабристлар ур., 2.